Әлеге таблицадан шуны әйтергә була: 2015-2016 нчы уку елы белән чагыштырганда, уртача билгенең 0,1% ка үсеше күзәтелә. Сыйфат һәм өлегрештә дә уңай якка үзгәрешләр бар: сыйфат 9,17 %ка, өлегреш 0,1 %ка арткан. Кызганычка каршы, “2”леләр саны үзгәрешсез, ләкин укучыларның саны узган уку елы белән чагыштырганда 34кә күбрәк икәнен исәпкә алсак, 0,1%ка уңай аерма күзәтелә.

2016 нчы елда 9 нчы сыйныф укучылары 4 фән буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен тапшырды. Шуларның 2 се – теләк бунча сайланган предметлар. Белем бирү оешмаларыннан 45 укучы татар теле һәм әдәбиятыннан имтихан тапшырырга җөрьәт итте. Нәтиҗәләр түбәндәгечә:

**2016 нчы елда ТДИ (ОГЭ) нәтиҗәләре**

| Төркем | Башкардылар | Уртача билге |
|---|---|---|
| Татар классларында белем алучылар | 16 | 3,69 (ТР-3,69) |
| Татар төркемнәрендә укучылар | 3 | 4,67 (ТР-3,97) |
| Рус төркеме укучылары | 12 | 3,42 (ТР-3,95) |
| Барлыгы | 31 | 3,9 (ТР-3,8) |

2016-2017 уку елында БРТ әзерләнү буенча, Ә.З. Рәхимов технологиясен тормышка ашыруга корылган педагогик остаханәләр планга кертелде. Боерык, план, исемлекләр электрон идарә аша белем бирү оешмаларына җибәрелде.

- Боерык №452, 03.10.2016 (Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе), 31 нче мәктәп;
- Боерык №453, 03.10.2016 (рус төркемнәрендә белем алучы 9 нчы сыйныф укучыларын БРТ әзерләү), 8 нче мәктәп;
- Боерык №460, 05.10.2016 (татар төркемнәрендә белем алучы 9 нчы сыйныф укучыларын БРТ әзерләү), 27 нче мәктәп;
- Боерык №463, 10.10.2016 (татар мәктәпләрендә, сыйныфларында белем алучы 9 нчы сыйныф укучыларын БРТ әзерләү), 2 нче гимназия.

Педагогик остаханәләрнең җитәкчеләре –муниципаль методик берләшмә җитәкчеләре Габдуллина К.Т., Насыйбуллина Д.Ф. һәм 2 нче гимназиянең татар телеһәм әдәбияты укытучысы Газизуллина Ә.Г.

Шулай ук 2016-2017 нче уку елыннан укучыларны олимпиадага әзерләү буенча ресурс үзәкләр булдырылды:

- Б. Урманче исемендәге 2 нче гимназия (татар мәктәпләрендә, сыйныфларында эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары);
- 5 нче мәктәп (татар төркемнәрендә белем бирүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары);
- 13 нче гимназия-интернат (рус төркемнәрендә укытучы педагоглар).

Укытучыларның педагогик компетентлыгын арттыру максатыннан, даими рәвештә төрле дәрәҗәдәге семинарлар үткәрелеп килә. 2016 нчы елда 1 нче һәм 2 нче гимназияләрдә Мәгарифне үстерү институтының милли лабораториясе методисты Мозафарова М.Г. җитәкчелегендә регионара семинарлар оештырылды. Семинарга Башкортстан республикасының Бишбүләк районы Ает мәктәбе укытучылары, Алабуга, Менделеевск, Тукай, Зәй, Яңа Чишмә районнары методистлары, укытучыларычакырылды. 2017 нче елда 31 нче мәктәп нигезендә Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясен өйрәнүгә корылган педагогик остаханәгә йомгак итеп республикакүләм семинар үткәрелде

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының күпчелеге матбугат аркылы белемнәрен күтәрү өстендә актив эш алып баралар, матбугат битләрендә эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар. 2015- 2016, 2016-2017 нче уку елларында “Мәгариф”, “Гаилә һәм мәктәп”, “Мәгариф. Татар теле” журналларына күмәк рәвештә язылу оештырылды. Әлеге журналларны укытучыларга таратуда җаваплылыкны 5 нче, 20 нче мәктәпләр, 13 гимназия-интернат үз өстенә алды.

Сәләтле балалар үсешен булдыру юнәлешендә укучылар өчен төрле дәрәҗәдәге олимпиадалар оештырыла. Әлеге юнәлештә татар теле укытучыларының максатчан эшчәнлекләре укучыларның уңышлары белән билгеләнә. 2009-2010 нчы уку елында милли олимпиадаларда 5 призлы урын булса, 2015-2016 нчы уку елында 21 укучы призлы урынга лаек булды. 2016-2017 нче уку елында гарәп, төрек телләреннән алынган алдынгы урыннарны кертеп, татар мәктәпләрендә укучы балалар өчен оештырылган рус теле һәм әдәбияты укучылары нәтиҗәләре белән 25 призлы урын билгеләнде.

Алдынгы укытучыларны барлау нияте белән, Түбән Кама муниципаль районында “Ел укытучысы” Бөтенроссия бәйгесенең муниципаль туры үткәрелә. 2016-2017 нче уку елында әлеге конкурста 18 татар теле һәм әдәбияты укытучысы үзара көч сынашты. Нәтиҗәдә 27 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Александрова А.И., 26 нчы мәктәп укытучысы Сәйфетдинова Ф.Х., 10 нчы мәктәп педагогы Шәмсетдинова Л.Ә. алдынгы урыннар яулады. Александрова А.И. “Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы” Бөтенроссия бәйгесендә “Укытучы-иҗатчы” номинациясендә җиңүче дип билгеләнде.

Иң яхшы укучыларны билгеләү максатыннан, ТРда төрле дәрәҗәдәге грантлар да гамәлгә кертелде. 2015-2016 нчы уку елында түбәндәге укытучылар грантка ия булдылар:

| №п/п | Укытучының Ф.И.О. | Белем бирү оешмасы | Грант |
|---|---|---|---|
| 1. | Бәдгыева Э.Д. | 31 нче мәктәп | ПНПО |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Фәттахова И.И. | 13 нче гимназия | ПНПО |
| 3. | Масаллимова М.М. | 32 нче гимназия | ПНПО |
| 4. | Насыйбуллина Д.Ф. | 8 нче мәктәп | укытучы-мастер |
| 5. | Мифтахова Э.Ф. | 14 нче лицей | укытучы-мастер |
| 6. | Шәмсиева Җ.М. | 32 нче гимназия | укытучы-мастер |
| 7. | Ибраһимова Э.Г. | 31 нче мәктәп | укытучы-мастер |
| 8. | Лотфуллина Г.Г. | 10 нчы мәктәп | укытучы-мастер |
| 9. | Хәмизова В.Т. | 7 нче мәктәп | укытучы-мастер |
| 10. | Хуҗанбердиева Ч.Т. | 35 нче лицей | укытучы-эксперт |
| 11. | Хәйруллина Г.Р. | 1 нче гимназия | укытучы-эксперт |
| 12. | Зарипова Ә.Г. | 2 нче гимназия | укытучы-эксперт |

**2016-2017 нче уку елында грантка ия булучы укытучылар**

| №п/п | Ф.И.О. | Белем бирү оешмасы | Грант |
|---|---|---|---|
| 1. | Насыйрова М.С. | 14 нче лицей | өлкән укытучы |
| 2. | Нәбиуллина Р.Х. | 31 нче мәктәп | өлкән укытучы |
| 3. | Александрова А.И. | 27 нче мәктәп | укытучы-мастер |
| 4. | Гыймранова З.М. | 25 нче гимназия | укытучы-мастер |
| 5. | Хуҗанбердиева Ч.Т. | 35 нче лицей | укытучы-эксперт |
| 6. | Зарипова Ә.Г. | 2 нче гимназия | укытучы-эксперт |
| 7. | Гәрәева Г.Ш. | Кама Аланы 2 нче мәктәбе | укытучы-эксперт |

Түбән Кама муниципаль районында төрле милләтләр үсешенә, аларны саклауга аеруча игътибар бирелә. Шул максаттан белем бирү оешмаларында ел саен Халыкара туган тел көненә багышланган әдәби-музыкаль кичәләр, фестивальләр, викториналар һәм башка чаралар үткәрелеп килә. Әлеге чараларда шәһәребездә эшләп килүче 11 милли оешма катнашында уза. Чараларда тамашачылар игътибарына татар, рус, башкорт, керәшен, чуаш, әзербәйҗан, әрмән, үзбәк, таджик, немец, украин милләтләренең сәнгате, мәдәнияте тәкъдим ителә: җырлар яңгырый, шигырьләр укыла, биюләр башкарыла. Бәйрәмдә кунак булып “Аксакаллар” шурасы әгъзалары, “Кама таңнары” әдәби берләшмәсе вәкилләре катнаша.

Әдәбият өлкәсендә яшь талантларны үстерү, аларга беренче адымнарын ясарга ярдәм итү - милли мәгарифнең бурычы. Шул максаттан, шәһәребездә 1998 нче елдан бирле Р.И. Вәлиев премиясенә яшь язучылар бәйгесе үткәрелеп килә. 19 нчы ел эчендә каләм тибрәтүчеләр бәйгесендә 1737 укучы катнашты.Әлеге елны бәйгедә катнашкан 59 укучының 22 се II турга үтте. Шулар арасыннан җиңүче, призерлар һәм номинантлар билгеләнде.

Татар халык, классик, заман җырларын популярлаштыру, сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру, татар теленә, татар халкының композиторларына, шагыйрьләренә һәм аларның әсәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләү максатыннан, ел саен шәһәребездә Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесе үткәрелә. Җыр бәйгесендә һәр ел меңнән артык бала катнаша. Сайлап алу турында уңай нәтиҗәләргә ирешкән хор коллективлары, ансамбльләр йомгаклау кичәсенә чакырыла, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге рәисе Р.М. Ганиев тарафыннан тантаналы рәвештә бүләкләнә. Әйтергә кирәк, “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесендә катнашу белем бирү оешмалары өчен зур стимул булып тора. Җиңү бәхетенә ирешкән

мәктәпләр акчалата бирелгән премия хисабына милли костюмнар тектерә. Алар мәктәп күләмендә генә түгел, муниципаль дәрәҗәдә үткәрелә торган чараларның йөзе булып тора.

Йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: Түбән Кама муниципаль районы мәгариф идарәсе милли мәгариф торышын үстерүгә зур җаваплык белән карый. Туган телебезнең торышы, аны саклап калу һәм үстерү, халкыбызның иң күркәм сыйфатларын кулланып, балаларга тәрбия бирүдә максатчан эш алып бара.

## ИҢ ЯХШЫ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫ

***Александрова Алсу Исмәгыйль кызы,***
*“Ел укытучысы -2017” муниципаль конкурсында “Иң яхшы ана теле укытучысы” номинациясендә 1 нче урын;*
*“Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы” Бөтенроссия бәйгесендә “Укытучы-иҗатчы” номинациясендә җиңүче*


*Александрова А.И.*

*Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача якын килү, аны яңача аңлауны таләп итә.Бу үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдында да яңа мәсьәләләр куя. Укытучылар, әлбәттә, бу яңарышны тормышка ашыруда төп рольне башкаралар. Укыту, тәрбия эшен яңарту яңа идеяләр, ысуллар, чаралар эзләү дигән сүз. Мәктәпнең бүгенге көндә бурычы - хәзерге көн таләпләренә, тормыш, җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирүче белемле, тирән фикер йөртә торган, социаль актив, карарны мөстәкыйль кабул итә торган иҗади шәхес тәрбияләү.*

*Ә андый шәхес тәрбияләү өчен, укытучы үзе югары мәдәниятле, әхлаклы, намуслы, яңалыкка, белемгә омтылучан, алга карап эш итә торган, һәр эшкә иҗади якын килүчән, ярдәмчел, таләпчән, бер сүз белән әйткәндә, үз эшенең остасы, уңышлы укытучы булырга тиеш, дибез.*

*Уңышлы укытучы – уңышлы укучы ул. Бүгенге заман укучысы көчле, үз сүзен әйтә алучы шәхесләргә ияреергә ярата. Укытучы укучы алдында, үзен уңышлы, актив, тормышта үз урынын тапкан, үз һөнәренең остасы итеп күрсәтә алмаса, үз үрнәгендә укучыларга тәрбия һәм белем бирә алыр микән?! Мин үземне уңышлы укытучы дип әйтә аламмы соң?*

*“Ел укытучысы -2017” муниципаль конкурсында татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында җиңү яулау миндә үз көчемә ышаныч, лидерлык сыйфатларын көчәйтте. Конкурс җиңелләрдән булмады. Башкача булырга да мөмкин түгел, укытучының һөнәри осталыгын бәяли торган төп бәйге бит ул. “Ел укытучысы -2017” конкурсының муниципаль турында ачык дәрес, мастер-класс, педагогик киңәшмә, белем бирү проектын яклау кебек бәйгеләр үткәрелде. Һәр бәйге укытучыны төрле яктан ачарга, һөнәри осталыгын дөрес бәяләргә мөмкинлек бирде. Ачык дәрес вакытында укытучыдан* ФДББС таләпләрен белү, таныш булмаган балалар күңеленә юл табу кебек педагогик осталык таләп ителсә, мастер-класста, иң беренче чиратта, эчтәлекнең тирән булуы, иҗади якын килү, эмоциональлек, оригинальлек, инновацион методлар куллану, проблемаларны ачыклау һәм аларны чишү юлларын күрсәтү, аудитория белән эшләү сәләте игътибарга алынды. Ә *педагогик киңәшмә, белем бирү проекты бәйгеләре укытучының һөнәри осталыгын гына түгел, аның командада эшләү сәләтен, лидерлык сыйфатларына да бәя бирергә мөмкинлек тудырды.*

*Чын лидер үсеш юлында тукталып калырга тиеш түгел. Аристотель сүзләре белән әйткәндә: “Алдагыларны куып җит, арттагыларны көтеп торма”.* “Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы” Бөтенроссия бәйгесенә катнашу педагогик һәм методик осталык үстерүдә, белемемне күтәрүдә, тәҗрибә алмашуда зур мөмкинлекләр ачты. Бәйгенең зона турында Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегеннән 53 укытучы, Россия Федерациясе төбәкләреннән 21 укытучы катнашты. “Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты

укытучысы” Бөтенроссия бәйгесенең йомгаклау турында зона этапларында җиңү яулаган 35 татар теле һәм әдәбияты укытучысы үзара көч сынашты. Казан мәктәпләрендә уздырылган ачык дәресләр, мастер-класслар, методик семинар, педагогик киңәшмә һәм белем бирү проекты биремнәре һәр укытучыга үз һөнәри осталыгын күрсәтергә мөмкинлек бирде.

Бәйгенең беренче турында дәрес һәм методик семинар үткәрү таләп ителде.*Мин 3 нче сыйныфта татар теле дәресен эш тәҗрибәмдә куллана торган үстерелешле укыту технологиясенә нигезләнеп үткәрдем. Бу технология укучыларда иҗади мәсьәләрне чишү ихтыяҗы, иҗади эшчәнлек өчен хас булган кызыксыну кебек омтылышлар тудырырга ярдәм итте.*

Ә методик семинарда «Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә универсаль укыту гамәлләрен формалаштыруда проект методы» дигән теманы яктырттым. Ни өчен нәкъ проект методы? Беренчедән, бу методны үземнең эш тәҗрибәмдә уңышлы кулланып киләм. Икенчедән, бу методны кулланганда УУГ дигән катлаулы процессның һәрбер “күзәнәге” дә эшкә җигелә дип уйлыйм. Семинар шушы тема нигезендә ике яклы мәгълүмат алмашуга, көнүзәк мәсьәләне чишүгә корылды. Мин жюри әгъзаларына педагогик проблеманы ачыклап, аны чишү зарурлыгын дәлилләдем, гамәли әһәмиятен ассызыкладым, проблема чишелешенең технологиясен тәкъдим иттем.

Икенче турда мастер-класс, педагогик киңәшмә һәм белем бирү проекты төзү кебек бәйгеләрдә үзеңнең һөнәри осталыгыңны күрсәтү таләп ителде. Мастер-классымның девизы итеп “Фикерләр өйрәтмә, фикерләргә өйрәт” дигән Иммануил Кант сүзләрен алдым. Фикри эзләнү - катлаулы процесс. Укучыларның эзләнү эшчәнлеге аша продуктив һәм иҗади фикер йөртү күнекмәләрен ничек үстерергә? Нинди технология, метод һәм алымнар бу максатка ирешергә мөмкинлек бирә? Мин шушы сорауларга җавап бирү максатыннан, иҗади фикер йөртү сәләтен үстерә торган “Сәйлән җыю” уенын тәкъдим иттем.

Педагогик киңәшмә “Уңышлы мәктәп. Проблемалар һәм казанышлар” дигән темага уздырылды. Мин Түбән Кама шәһәре мәктәпләрендәге казанышлар турында сөйләдем, проблемалар һәм аларны чишү юлларын күрсәтеп киттем.

Белем бирү проекты бәйгесендә конкурсатларны өч төркемгә бүлделәр. Безнең төркем “Уңышлы укучы маршруты” проектын тәкъдим итте. Шушы проектны тормышка ашыру өчен “В контакте” социаль сайтында үзебезнең төркемебезне булдырдык һәм ул бүгенге көндә дә безне тыгыз бәйләнештә тота (https://vk.com/tataruku).

“Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы” Бөтенроссия бәйгесендә “Укытучы-иҗатчы” номинациясендә җиңү яулау минем өчен зур җиңү һәм зур казаныш булды. Бу бәйге миңа осталык, тәҗрибә тупларга мөмкинлек бирде, үз-үземә ышаныч уятты, яңа дуслар, фикердәшләр табарга ярдәм итте.

## МИН - УКЫТУЧЫ

***Сәйфетдинова Фәридә Хәсәнша кызы,***
*26 нчы урта мәктәбенең югары*
*квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


*Сәйфетдинова Ф.Х.*

Талгын гына җыр агыла... Бу җыр - безнең яшьлегебез җыры бит. Галиҗанәп җыр, син мине еракларга алып китәсең, кадерле хатирәләрне яңартасың...

Мин яшьлегем эзләрен саклаган Арча урамыннан атлыйм. Менә ул Изге уку йорты - мин дүрт ел укыган, укытучы булам дип, ак хыял канатларында ашкынып килгән мәгърур белем йорты.

Беренче дәрес бирү шатлыклары, балалар белән очрашудан алган тәэсирләр, безгә сынап карашучы, ышаныч белдерүче укытучылар... Әле кичә генә булган кебек. Колагымда укытучыларыбызның тавышлары ишетелгәндәй була: “Исәнмесез, балалар! Дәресебезне башлыйбыз.”

Шигъри җанлы Гөлсинә апаның дәресләре күз алдыннан үтә. Класс җитәкчебез Венера апаның һәрберебез турында әниебез кебек кайгыртуларын, музыка серләрен ачучы Зилә Зәкиевнаның моңлы тавышын, директорыбыз Илдус Габдрахмановичның киңәшләрен ишеткәндәй булам. Рәхмәт Сезгә, хөрмәтле остазларыбыз!

Без дәресләрдә бик еш укытучы нинди булырга тиеш дигән сорауга җавап эзли идек. Еллар үткәч аңладым: чын укытучы безнең остазларыбыз кебек булырга тиеш икән. Казан дәүләт педагогия институтында укыганда да, мәрхәмәтле мөгаллимнәребезнең мәхәббәтен, игътибарын тоеп укыдым.

Мин - укытучы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Ә каршымда- эчкерсез, самими балалар. Алар, сораулы карашларын төбәп, укытучы апаларыннан җавап көтәләр. Укучыларымның өметләрен аклый алырмынмы, күңелләренә яхшылык орлыклары, белемгә омтылыш, туган телебез белән горурлану, әдәбиятыбызга кызыксыну тәрбияли алырмынмы дигән сорау белән башланган вакыттанда күп вакыт үткән. Эшләгән саен сораулар арта гына бара...

Укытучы - иң беренче чиратта, балаларны яратучы, белем алуга ихтыяҗ, кызыксыну уятучы кеше. Һәр баланың үз дөньясы. Ә ул дөньяның ишекләрен ачып, түргә үтәргә сабырлык та, зирәклек тә кирәк. Минемчә, дәрес уңышлы узсын өчен, сыйныфта уңай халәт булырга тиеш. Укучы белән укытучы арасындагы ышанычлы мөнәсәбәт белем алу өчен иң кирәкле шарт булуын онытырга ярамый.

Төрле укучылар бар: алар мөмкинлекләре белән дә, сәләтләре белән дә бер-берсеннән бик нык аерылалар. Минем каршымда кемнеңдер газиз баласы, ул бик талантлы дигән принциптан чыгып эшләргә тырышам. Укучылар беркайчан да үзләрен кем белән дә булса чагыштырганны яратмыйлар. Дәрестә баланың күңеленә ачкыч табып, кечкенә генә уңышка ирешерлек мөмкинлек тудырсаң, аның иңнәренә канатлар үскәндәй була. Укытучы өчен балаларны сөендерүдән дә ләззәтлерәк, бала ышанычын алудан да кадерлерәк нәрсә булырга мөмкин?

Татар теле һәм әдәбияты дәресләренең төп бурычы – туган телебез,милләтебез сакчылары тәрбияләү, укучыларның рухи дөньясын баету, дөньядагы вакыйга-күренешләргә дөрес бәя бирү, рухи камиллеккә омтылу.

Без зур тизлекләр, яңа технологияләр заманында яшибез. Тормыш ритмына җитешү өчен, туктаусыз чабабыз, ашыгабыз, туктап уйланырга вакыт калмый. Бәлки шуңадыр, балалар әдәби әсәрләр укуны юкка вакыт әрәм итү дип саныйлар. Өч-дүрт сәгатьтә әсәрне интернеттан, телевизордан карап булганда, нигә аны укып торырга, дип фикер йөртәләр. Әдәбият укыту ул-вакыт уздыру өчен, китап укырга гына өйрәтү түгел. Әдәбият- безнең балаларыбызның күңелен сафландыра, рухларын баета, җаннарын тәрбияли торган фән. Күңеле надан, җаны тар кешедән дә куркыныч җан иясе юк. Бу турыда бер минутка да онытырга ярамый.

Әдәбиятка, туган телгә игътибарны киметеп, без кешене җирлегеннән аерабыз. Патриотизм абстракт төшенчә түгел, ул – конкрет. Олы ватанга мәхәббәтне туган җиргә, аның теленә мәхәббәттән генә тәрбияләп була. Үз әнисенең теленнән бизгән кеше бүтән аналарның телен беркайчан да хөрмәт итә белми. Бу – хакыйкать", - дип язган чорыбызның күренекле шәхесе Туфан Миңнуллин.

Язучының җанлы телен, сүзнең  тәэсир көчен, аһәңен тою өчен, кулыңа китап алырга кирәк. Аны бернинди компьютер да алыштыра алмый.

Яшьләрдә – экран-китап.

Кызык та ул, яңа да.

...Кәгазь китап охшап калды

Рәнҗетелгән анага, - дип ачынып яза шагыйрь Равил Фәйзуллин.

Матур әдәбиятка мәхәббәтне кулга китап тотмыйча, аны укымыйча тәрбияләп булмый, дип саныйм мин. Китапханәләргә экскурсия, диспут, конференция, дәрес-презентацияләр үткәрү – бу максатка ирешү юлларының кайберләре генә. Үзебезнең төбәк язучылары белән очрашуларны укучылар көтеп алалар, үзләрен кызыксындырган сорауларына җавап табып

кына калмыйча, рухланып иҗат итә башлыйлар. Укучыларның очкын чәчеп торучы күзләрен, синең дәресләреңнән канәгатьлек хисе алып, рәхмәт ишетүдән дә зуррак бәя бармы икән укытучы өчен?! Шушы рәхәт мизгелләр өчен булса да, эшләргә була укытучы булып!

Әдәбият дәресләрендә программага кертелмәгән, бүгенге көндә актуаль, укучыларны кызыксындыра торган әсәрләр белән таныштырырга яратам. Тарихыбызга, туган җиребезгә мәхәббәт, күренекле шәхесләребез белән кызыксыну әдәбият дәресләреннән башлана да инде. Балалар тарихыбызга битараф түгел, халкыбыз, телебез язмышы аларны да борчый. Алар үз фикерләрен кыю итеп әйтеп бирә беләләр. Укытучы өчен күп кирәк мени, эшеңә моннан да зур бәя була алмый. Дәресләрдән, үз эшеңнән рәхәтлек алу – педагогик осталык җимешеме, әллә күп еллык тәҗрибәме, анысын әйтә алмыйм - шулай да укучыларымның уңышларын үземнең эшемнең билгеле бер системасы, нәтиҗәсе дип саныйм.

Балалар белән олимпиадаларга, иҗади бәйгеләргә әзерләнергә яратам. Аларның уңышларына укучылардан да күбрәк сөенәмдер, мөгаен. “Укытучы – дөньяның аерым категориядәге бер кешесе. Аның шатлыгы да, кайгысы да кешенеке төсле түгел”, - дип Мөхәммәт Мәһдиев ничек дөрес язган?!

Дәресләрдә, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүнең төрле юлларын кулланырга тырышам. Укучымның иҗади эшендә ”Әгәр мин тылсымчы булсам, мин яхшылык кына эшләр идем. Яхшы эшләр бик күп алар. Авыру кешене терелтү, мохтаҗларга ярдәм итү, сугышларны туктату өчен, бөтен көчемне куяр идем. Дөньядагы бар халыкны бәхеттә, муллыкта, сәламәтлектә яшәтер идем. Мин тылсымчы түгел, әмма бу хыялымны тормышка ашыру өчен, бик тырышачакмын, көчемне кызганмаячакмын”, - дип язуы минем кыйбламның дөрес юлдан булуын күрсәтә дип саныйм мин. Димәк, яхшылык орлыклары ундырышлы җиргә төшеп шытып чыкканнар, ныгып үсеп киләләр. Укучыларымның уңышлары – минем хезмәтем җимешләре. Мин алар белән горурланам.

Рәхмәт сиңа, язмыш, мине мәктәп белән бәйләгәнең өчен,башка юлга кертмичә, балачак һәм яшьлек илендә калдырганың өчен. Минем бар җиһанга: “Мин - укытучы, укытучы - иң кирәкле һөнәрләрнең берсе!” - дип, бар кеше ишетерлек итеп әйтәсем килә.

Ә җыр яңгырый да яңгырый...

## БАЛАЛАРГА ИНДИВИДУАЛЬ ЯКЫН КИЛЕП

***Шәмсетдинова Ләйсән Әсфән кызы,***
*10 нчымәктәпнең I нчеквалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



*Шәмсетдинова Л.Ә.*

Мин - Шәмсетдинова Ләйсән Әсфән кызы, I нче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Мин үзем тумышым белән халкыбызга бөек шагыйребез Г. Тукайны биргән көйле, моңлы Арча якларыннан. Хәзерге көндә 10нчы урта гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшлим. Минем гомуми эш стажым 18 ел, татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак -14 ел.

Әйе, укытучы эше җиңел эш түгел. Аның төп эше белем бирү булса да, бүтән вазыйфалары да күптөрле: ул укучыларына яхшы әни дә, киңәшче дә, тугры дус та була белергә тиеш. Мин укучыларыма өйрәнүче итеп түгел, чын дус, сердәш, киңәшче итеп карарга тырышам. Алар дәрестә куркып утырмасыннар, уйлансыннар, сораулар бирсеннәр, кызыксынсыннар, һәм аларның иҗади сәләтләре калкып чыксын. Һәр бала үзе бер кечкенә дөнья бит ул. Аларның холык-фигыльләре төрле булган кебек, уку материалын үзләштерү дәрәҗәсе дә төрле. Моны һәрдаим игътибар үзәгендә тотам. Шуңа күрә укытуның төрле алымнарын кулланам. Иҗади үстерелешле укыту технологиясеннән файдалану – шуның ачык мисалы.

Татар теле укытучысы буларак, минем төп максатым - укучыларымда татар теленә кызыксыну уяту, татар теленә хөрмәт хисе тәрбияләү, һәм иң мөһиме – аларны татарча сөйләшергә өйрәтү. Чөнки бүгенге көндә укытуның төп максаты - иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү. Һәм мин шушы максатны чынга ашыру өчен, рус телле балаларны татар теленә төрле технологияләр кулланып өйрәтәм: коммуникатив технология, компьютер технологияләре, уен һәм сәламәтлекне саклау технологиясе, проблемалы укыту технологиясе һәм проектлар методы. Бу технологияләрне куллану хезмәтемдә уңай нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Минем укучыларым инде менә 5 ел рәттән шәһәр олимпиадаларында призлы урыннар алып киләләр.

Үзенең үсеше өстендә эшләмәүче укытучы беркайчан да иҗади шәхес тәрбияли алмаячак. Укытучы үзенең профессиональлеген, компетентлыгын үстерү өстендә һәрдаим эшләп торганда гына, укытуның һәм педагогик процессның сыйфатын күтәреп булачак.Үзем иҗади һәм заман педагогы буларак, мин профессиональ компетентлыгымны төрле чаралар ярдәмендә үстерергә тырышам. Шундый чараларның берсе булып төрле конкурслар тора. Быел мин,“Ел укытучысы -2017” бәйгесендә катнашып, “Иң яхшы туган тел укытучысы” номинациясе белән финалга чыктым. Бу бәйгедә катнашу миңа үземнең тупланган педагогик тәҗрибәмне күрсәтергә, профессиональ үсешкә тагын бер адым алга атларга, үз-үземне чыдамлыкта, психологик ныклыкта тикшереп карарга булышты дип уйлыйм мин.

## БЕЗ АЛДЫНГЫ УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАБЫЗ

***Хуҗанбердиева Чулпан Тимергали кызы,***
*Түбән Кама муниципаль районы “35 нче лицей” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


*Хуҗанбердиева Ч.Т.*

Чулпан Тимергали кызы – ике дистә елга якын хезмәт тәҗрибәсе булган иҗади шәхес, эзләнүчән педагог, яңалыкка омтылучы белгеч, заманча технологияләрдән уңышлы файдаланучы энтузиаст укытучы. Ул укыту-тәрбия методикасын яхшы үзләштерү белән бергә бу процесска яңалык кертүче, аны тормышка ашыру һәм тарату өстендә эшләүче алдынгы укытучы. Аның һәр дәресе – иҗади эзләнүләр нәтиҗәсе. Ул укыту-тәрбия процессында төрле заманча методик технологияләрдән, аеруча мәгълүмати-коммуникацион, проблемалы-эзләнү технологияләреннән уңышлы файдалана, ә әдәбият дәресләрен А.Г. Яхин системасы буенча алып бара.

Аның укучылары ел саен район һәм республика күләмендә үткәрелгән татар теле һәм әдәбияты бәйгеләрендә җиңү яулыйлар. 2015/2016 нчы уку елында Миннегулова Заринә татар әдәбияты буенча республика күләмендә үткәрелгән бәйгедә - җиңүче, Әхмәтова Эльвина, Минхаерова Диана, Сабанова Алинә - призерлар; Андрющенко Елена - татар теленнән рус телле укучылар арасында үткәрелгән республика олимпиадасында –призер; 2016/2017 нче уку елында 8 нче сыйныф укучылары Әхмәтова Эльвина, Минхаерова Диана, Сабанова Алинә татар әдәбияты буенча республика күләмендә үткәрелгән бәйгедә - призерлар, ә Андрющенко Елена – V Халыкара татар теле һәм әдәбияты олимпиадасы лауреаты. Соңгы 3 ел дәвамында Чулпан Тимергалиевнаның татар теле һәм әдәбияты буенча район олимпиадасында 28 укучысы җиңүче һәм призер булды.

Һәрчак ярдәм кулы сузарга әзер укытучы мәгариф хезмәткәрләренең edu.tatar.ru порталында (https://edu.tatar.ru/community/index/1600), укытучының шәхси сайтында (https://infourok.ru/user/huzhanberdieva-chulpan-timergalievna), ТР укытучыларының профессиональ үсеш порталында (https://uchiteltatarstan.ru/Expert), belem.ru сайтында үз хезмәтләрен урнаштырып бара. Һөнәри конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнаша. Хужанбердиева Ч.Т. - “Мәгариф” өстенлекле илкүләм проекты җиңүчесе

(2013, 2015 нче еллар). 2011-2014 нче елларда “Иң яхшы укытучы” республика конкурсында катнашып, 4 ел рәттән әлеге грантка ия булды. Шулай ук Чулпан Тимергалиевна - ТР мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан үткәрелгән “Укытучы – тикшеренүче” (2011) һәм “Укытучы-эксперт” (2016, 2017 нче еллар) гранты иясе, Түбән Кама районы муниципаль башлыгының мәгариф өлкәсендә үткәрелүче конкурста “Укучыларның фәнни-эзләнү эшчәнлеген оештыру” (2012) һәм “Милли мәгариф һәм мәдәниятне үстерү” (2016) номинацияләрендә җиңүче.

Тырыш хезмәте, яшь буынны укыту һәм тәрбияләүдә ирешкән уңышлары өчен 2013 нче елда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2015 нче елда “Түбән Кама муниципаль районы” Мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Балаларга шәхес буларак каравы нәтиҗәсендә Чулпан Тимергали кызының укучылар һәм ата-аналар арасында авторитеты зур. Укучылар аны яраталар, үз итәләр. Ул аларның өлкән дусты да, киңәшчесе дә, сердәшчесе дә.

## ШӘМСИЕВА ҖИҺАНИЯ МӘГЪСҮМ КЫЗЫ - ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ “32 НЧЕ ГИМНАЗИЯ” МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ КВАЛИФИКАЦИОН КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ



Җиһания Мәгъсүм кызы яңа педагогик технологияләр куллану, профессиональ осталыгын үстерү буенча максатчан эшчәнлек алып бара. Гимназия, муниципаль, республика күләмендә үткәрелгән конференцияләрдә, “Педагогик осталык” иҗади-тәҗрибә төркемендә катнаша, тәҗрибә уртаклаша. Аның укучылары республика һәм шәһәр күләмендә үткәрелгән фәнни-гамәли конференцияләрдә, олимпадаларда, сәнгатьле шигырь сөйләү һәм иҗади бәйгеләрдә җиңү яулыйлар.

Татарстан халыклары Ассамблеясының Түбән Кама филиалы Грамотасы (2012), Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге һәм Түбән Кама мәгълүмати-методик үзәге Рәхмәт хатлары (2012), Түбән Кама мәгълүмати-методик үзәгенең I, II, III дәрәҗәле Дипломнары (2013, 2014, 2015) белән бүләкләнә. Җиһания Мәгъсүм кызы укучыларның татар теле һәм әдәбияты буенча республикакүләм олимпиаданың муниципаль этабы эшләрен тикшерү буенча комиссия әгъзасы (2011-2015), укучыларны республика олимпиадасына әзерләү буенча Олимпиада үзәгенең педагогы, “Укучыларны Бердәм республика тестына әзерләү” исемле педагогик остаханәнең әгъзасы, “Укытучы-мастер” республика гранты җиңүчесе (2016).

“II һәм III Республика Гамил Афзал укулары” исемле фәнни-тикшеренү конференцияләрендә чыгыш ясый, II һәм III дәрәҗәле дипломнар белән бүләкләнә (2013, 2014). Эш тәҗрибәсе “Мәгариф” электрон журналында (2015), Бөтенрәсәй иҗади эшләүче педагоглар фестивале сайтында бастырылды.

**“Телләр белгән – илләр белгән”, – ди халык мәкале. Телләр өйрәнү бүгенге көндә белем бирү системасында мөһим урын алып тора.** Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле өйрәтүне нәтиҗәле оештыру – Җ.М. Шәмсиеваның төп бурычы. Аның укучылары Кустова Татьяна, Логунова Ксения – татар теле һәм әдәбияты буенча республикакүләм олимпиаданың муниципаль этабы призерлары (2013, 2014). Җиһания Мәгъсүмовна җитәкчелегендә укучылар фәнни-тикшеренү эше белән нәтиҗәле шөгыльләнәләр: Ахунова Диана – Вернадский исемендәге Бөтенрәсәй яшьләр тикшеренү эшләре конкурсы лауреты (2013), Хөснуллин Илназ, Бәдретдинова Айгөл – “Динамика полиэтнических и поликонфессиональных отношений Российской цивилизации” муниципаль фәнни-гамәли конференция призерлары (2013, 2014), Бәдретдинова Айгөл – «Дебют в науке» VI Республика укучыларының тикшеренү һәм проект эшләре конкурсы призеры (2015). Аның укучылары төрле конкурсларда актив катнашалар, яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр: Бәдретдинова Айгөл – “Яттан сөйлә Тукай шигырьләрен, шушы булыр иң зур бүләгең”

муниципаль шигырь сөйләү бәйгесендә II тур җиңүчесе (2014), “Көйле, моңлы татар җыры – 2014” хорлар конкурсы – II урын, “Көйле, моңлы татар җыры – 2015” хорлар конкурсы – I урын, Гарифуллина Нәргизә, Бәдретдинова Айгөл – “Киләчәккә билет” муниципаль сочинениеләр конкурсы призёрлары (2015).

Җиһания Мәгъсүм кызы балаларны һәрчак аңлый, ярдәм кулы суза. Укучыларның кечкенә генә шатлыгы да аның өчен олы куаныч. Әти-әниләр белән тыгыз элемтәдә булу, шәхси якын килеп, һәр бала белән иҗади эшләү нәтиҗәсендә аның укучылары белемле һәм тәрбияле булып, татар телен яратып үсәләр.

## МӘСӘЛЛИМОВА МӘҮЛИЯ МИНВӘЛИ КЫЗЫ – ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ “32 НЧЕ ГИМНАЗИЯ” МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ ЮГАРЫ КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ



Ул үз алдына һәрвакыт максат куеп, укучыларны ныклы белемле, тиешле күнекмәләргә ия булырлык, иҗади эшләүче, заман белән бергә атлаучы кешеләр итеп тәрбияләү өчен алдынгы технология элементларын кулланып эшли. Мәүлия Минвәли кызы “ФГОС шартларында татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди фикерләү технологиясен куллану аша укучыларның белем сыйфатын күтәрү” дигән методик тема буенча эшли.

Мәүлия Минвәли кызы “Образование” өстенлекле милли проектның “Яхшы укытучы” бәйгесенең Татарстан Республикасы күләмендә җиңүчесе (2016), “Безнең иң яхшы укытучы” республикакүләм Гранты иясе (2011, 2012, 2014).

Татар әдәбиятыннан республикакүләм олимпиадага призерлар әзерләгән өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы (2014, 2015, 2016, 2017), Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Рәхмәт хаты (2014, 2015, 2016) белән бүләкләнде.

“II һәм III Республика Гамил Афзал укулары” исемле фәнни-тикшеренү конференцияләрендә уңышлы чыгыш ясап, III дәрәҗәле дипломнар белән бүләкләнде (2013, 2014). Эш тәҗрибәсе “Мәгариф” электрон журналында (2015) бастырылды.

Мәүлия Минвәли кызы укучыларның татар теле һәм әдәбияты буенча республикакүләм олимпиаданың муниципаль этабы эшләрен тикшерү буенча комиссия әгъзасы (2010-2017), укучыларны олимпиадага әзерләү буенча ресурс үзәгенең педагогы, “Укучыларны Бердәм республика тестына әзерләү” исемле педагогик остаханәнең әгъзасы булып тора.

## ХӘЙРУЛЛИНА ГӨЛНАЗ РӘШИТ КЫЗЫ – ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ 1НЧЕ ГИМНАЗИЯНЕҢ ЮГАРЫ КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ



Хәйруллина Г.Р. муниципаль район татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен һәрдаим ачык дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар күрсәтә, семинарларда чыгышлар ясый. “Бердәм республика тестына әзерлек” чыгышы, “Моңлы бер җыр”, “Әбием сандыгы” форумнары, “Синтаксик синонимнар”, “Ак яулыклы ак әбиләр” ачык дәресләре укытучыны үз эшенең остасы итеп танытты.

Гөлназ Рәшит кызы – укытучыларның “Педагогик осталык” Бөтенроссия иҗади-тәҗрибә төркеме катнашучысы. Тикшеренү эшенең темасы – “10 нчы сыйныфта татар телен тирәнтен укыту программасы”. Мәгариф хезмәткәрләренең ns.portal.ru социаль челтәрендә үзенең шәхси педагогик сайты булдырылды.

Һәр уку елында Хәйруллина Г.Р. укучылары муниципаль һәм республика олимпиадаларында җиңүче һәм призёр булалар. Соңгы 3 ел эчендә ул татар теле һәм

әдәбияты буенча республикада 3 призёр, муниципаль районда 27 призёр һәм 6 җиңүче әзерләде. КФУ тарафыннан үткәрелә торган фән олимпиадаларында Гаффарова Сөмбел һәм Вафина Айсылу дүрт ел рәттән җиңүче булдылар. Укучылар төрле бәйгеләрдә дә үзләрен сынатмыйлар. 2014нче елда "Туган телем-серле тел" республика бәйгесендә Абдуллин Марат - "Экология" номинациясе җиңүчесе. Камалиева Ландыш "Умырзая" республика бәйгесендә Гран-прига лаек булды. "Коррупциягә - "Юк!" республика бәйгесендә Абдуллин М. абсолют җиңүче дип танылды һәм Республика Иҗимагый палатасы Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

2014нче елдан башлап, Хәйруллина Г.Р. бердәм республика тестының киңәйтелгән җавапларын тикшерү буенча Казан шәһәрендә эксперт комиссия составында эшли. Муниципаль районда татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиада тикшерү комиссиясе әгъзасы. 2011, 2012, 2013нче елларда "Иң яхшы укытучы" республика гранты иясе. Гөлназ Рәшит кызы 2016нчы елда шәһәр Башлыгы грантының "Милли мәгариф һәм мәдәниятне үстерү" номинацисендә икенче урынга лаек булды. Шул ук елда "Укытучы-эксперт" республика гранты җиңүчесе.

## ЗАРИПОВА ӘНИСӘ ГАЗИЗУЛЛА КЫЗЫ - ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАКЫЙ УРМАНЧЕ ИСЕМЕНДӘГЕ 2 НЧЕ ГИМНАЗИЯ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИОН КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ



Әнисә Газизулла кызы "Образование" өстенлекле милли проектның "Яхшы укытучы" бәйгесенең Татарстан Республикасы күләмендә җиңүчесе (2012, 2014), "Безнең иң яхшы укытучы" республикакүләм Гранты иясе (2011, 2012, 2014), "Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын- кыз карашы" республикакүләм бәйгесенең "Елның үрнәк хатын-кызы" номинациясендә зональ турда җиңүче (2012), Түбән Кама муниципаь районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе тарафыннан оештырылган Түбән Кама муниципаль районы башлыгы ГРАНТЫ бәйгесенең "Тәҗрибә һәм интеллект" номинациясендә җиңүче (2013), Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе тарафыннан оештырылган Түбән Кама муниципаль районы башлыгы ГРАНТЫ "Милли мәгариф һәм мәдәниятне үстерү" бәйгесе номинациясендә җиңүче (2015), Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларындагы укытучыларның һөнәри осталыкларын үстерү буенча "Укытучы- эксперт" бәйгесенең Грант иясе (2016, 2017)

Татар теле һәм әдәбиятыннан республикакүләм олимпиадага призерлар әзерләгән өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы (2011, 2012, 2013, 2016), Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Рәхмәт хаты (2011, 2012, 2013, 2016) белән бүләкләнде.

Әнисә Газизулла кызы - 9 нчы сыйныф укучыларының Бердәм республика тестының иҗади бирем өлешен тикшерү буенча Республикакүләм комиссия әгъзасы, эксперт (2014-2017), Түбән Кама муниципаль уку йортларының 2016- 2017 нче уку елына әзерлеген тикшерү буенча комиссия әгъзасы, укучыларның татар теле һәм әдәбияты буенча республикакүләм олимпиаданың муниципаль этабы эшләрен тикшерү буенча комиссия әгъзасы (2011-2017), рәисе (2015, 2016), укучыларны республика олимпиадасына әзерләү буенча Олимпиада үзәгенең педагогы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе тарафыннан оештырылган Түбән Кама муниципаль районы башлыгы ГРАНТЫ "Милли мәгариф һәм мәдәниятне үстерү" номинациясенә укытучыларның эшчәнлеген бәяләү буенча комиссия әгъзасы (2016-2017), "Ел укытучысы-2017" бәйгесенең җюри әгъзасы, "Укучыларны Бердәм республика тестына әзерләү" исемле педагогик остаханәнең җитәкчесе.

2016 нчы елда Хәсәншина Ләйлә татар теле һәм әдәбияты буенча үткәрелгән халыкара олипиадада II дәрәҗә дипломга, татар теле һәм әдәбияты буенча үткәрелгән республикакүләм олимпиадада призер исеменә лаек булды. Татар әдәбияты буенча республикакүләм олимпиадада Вагыйзова Алсу, Зиннатуллина Лилия - призер, Казан (Идел буе) федераль дәүләт университеты тарафыннан оештырылган татар теле фәне буенча үткәрелгән олимпиадада 2 призер һәм 1 җинүче (2015-2017), Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты филиалы тарафыннан оештырылган татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадада 2 җиңүче, 2 призер (2015, 2017), татар әдәбияты буенча үткәрелгән "Әдәби марафон" исемле олимпиадада 1 җиңүче, 5 призер (2016), татар теленнән "Эрудит" исемле республикакүләм олимпиадада 3 призер (2017) урыннары яуланды.

Укучылар 2014-2017 нче еллар дәвамында республика олимиадасының муниципаль этабында татар теле һәм әдәбиятыннан 20 җиңүче һәм призер дәрәҗәсенә ия булдылар.

"Татар теле һәм әдәбияты: үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге" исемле Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциядә Мәхмүтова Алия һәм Нуриев Азат I дәрәҗә, Хатыйпова Таңсылу III дәрәҗә дипломга, "Мин – тикшерүче" республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә Нуриев Азат I дәрәҗә, "Үз тамырларыңны белеп яшә.." исемле республикакүләм фәнни-тикшерену конференциядә Минебаева Гүзәл II дәрәҗә дипломга лаек булдылар.

Әнисә Газизулла кызы 2016 нчы елның сентябрь аеннан декабрь аена кадәр "Укытучы-мастер" бәйгесендә җиңгән түбәндәге Түбән Кама муниципаль районы укытучыларының проект эшчәнлегенә юнәлелеш бирде, тикшерде, бәяләде, методик ярдәм күрсәтте:

- башлангыч сыйныф укытучысы – Чумакова Ольга Николевна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы- Насыйбуллина Дифинур Фаварисовна (8 нче гомуми белем бирү мәктәбе)

- башлангыч сыйныф укытучысы – Чагина Светлана Владимировна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы- Мифтахова Эльмира Флуровна ( 14 нче юридик лицей)

- башлангыч сыйныф укытучысы – Петрунина Нәзилә Расимовна, хезмәт укытучысы - Морзаханов Марат Әхмәтович (Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназия)

Укытучы – мастерлар эшләгән проект укучыларны эзләнү, тикшерену, логик фикер йөртү күнекмәләренә өйрәтү белән берррәттән, үз эшеңнең нәтиҗәсен күрә белергә юнәлдерелгән гамәли максталарга ярашлы нәтиҗәле эшчәнлеккә нигезләнгән иде.

2017 нче елының май аеннан ноябрь аена кадәр Әнисә Газизулла кызы "Укытучы- мастер" бәйгесендә җиңгән Түбән Кама муниципаль районы укытучылары: Гыймранова Зәрия Мугавиевнага (25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе), Леонова Наталья Анатольевнага (3 нче гомуми белем бирү мәктәбе) проект эшчәнлегенә тема сайлау, юнәлеш бирү, бәяләү буенча методик ярдәм күрсәтәчәк.

## ХӘМИЗОВА ВАФИЯ ТИМЕРШАЕХ КЫЗЫ - ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ 7 НЧЕ ГОМУМИ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕНЕҢ I КВАЛИФИКАЦИОН КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ



Замана укучысына әзер белемнәрне үзләштерү һәм тиешле күнекмәләр булдыру гына җитми. Иҗади, мөстәкыйль, җаваплы булырга өйрәтү бурычы барлыкка килә. Шушы бурычларны тормышка ашыру максатыннан Вафия Тимершаех кызы үз эшчәнлегендә һәрвакыт иҗадилыкка омтыла. Укучыларының район, республика күләмендә үткәрелгән төрле чараларда катнашып үрләр яулавы әлеге эшнең нәтиҗәсе булып тора. "Үз тамырларыңны белеп яшә.." исемле республикакүләм фәнни-тикшерену конференциясе III дәрәҗә диплом; Туфан Миңнуллин исемендәге укытучыларның һәм укучыларның III республика конференциясе лауреат; Галим-мәгърифәтче И. Хәлфин исемендәге XII республикакүләм фәнни-тикшерену конференциясе II дәрәҗә диплом; С.С. Молодцов исемендәге XV ачык республикакүләм фәнни-тикшерену конференциясе III дәрәҗә диплом; "Мин – тикшерүче"

республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе III дәрәҗә диплом, “Яшь филолог” республикакүләм фәнни-практик конференциясе II дәрәҗә диплом; Гамил Афзал исемендәге иҗат фестивале II дәрәҗә диплом.

В.Т. Хәмизованың укучылары ел да татар теленнән олимпиадаларда призлы урыннарга лаек булалар: 2014 нче елда 1 призёр, 2015 нче елда 2 призёр, 2016 нчы елда – 3 призёр, 2017 нче елда – 2 призёр. Мөхәммәтҗанова Алия 2015 нче елда татар теле һәм әдәбияты буенча үткәрелгән халыкара олипиадада III дәрәҗә дипломга лаек булды.

2016 нчы елда Вафия Тимершаех кызы “Укытучы- мастер” республикакүләм гранты иясе.

## ЛОТФУЛЛИНА ГӨЛИЯ ГАРИФ КЫЗЫ - ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ 10НЧЫ УРТА МӘКТӘБЕНЕҢ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ



«Укытучы-мастер» гранты җиңүчесе Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләп иткәнчә, заманча укытучының максаты – уйларга, фикер йөртергә сәләте булган, заман белән бергә атлаучы, уйлап табучан, үз халкының тарихын, мәдәниятен яхшы белүче иҗади шәхес тәрбияләү. Әлеге максатны укытучы бары тик укыту процессында гына чынга ашыра ала. Шуңа да ул бер урында таптанып тормыйча, шәхес буларак иҗади яктан эш итсә, ниндидер яңалык эзләсә, уйлап тапса гына ниндидер нәтиҗәгә ирешә.

Укытучының осталыгын укучылары нәтиҗәләреннән дә күрергә була. Гөлия Гариф кызының укучылары – шәһәр һәм республика олимпиадалары җиңүчеләре, шулай ук төрле конкурс, конференцияләрдә дә нәтиҗәле чыгышлар ясыйлар. Укытучы соңгы биш елда өч грантка ия булган, шулай ук, ТР министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнгән. Укучыларга татар теленнән белем бирү белән генә чикләнмичә, аларның осталыкларын үстерү, туган ягыбызга, милли мәдәниятебезгә мәхәббәт тәрбияләү өстендә дә эшләве ТР мәдәният Министрлыгы рәхмәт хаты белән билгеләнә.

Туган якны ярату гаиләдән, мәктәптән, туган шәһәрдән башлана. ТР укытучылары арасында оештырылган “Укытучы–мастер” конкурсында катнашып, Түбән Каманың юбилеена бүләк рәвешендә, балалар шагыйрәсе Рәмзия Вәлиева шигырьләре нигезендә, “Трамвайда Түбән Камага шигъри сәяхәт” дип аталган проект әзерләнә. Проект ике этапка бүленә: беренчесендә авторның шәһәребез матурлыгына, кешеләренең батырлыгына дан җырлаган шигырьләрен трамвайда сөйләү, икенчесендә видеоязма әзерләү, аны киң җәмәгатьчелеккә җиткерү максаты куела. Укучылар максатларына ирешәләр. Шәһәр телевидениесе проектны үз каналында яктырта, җирле газеталарда укучылар үз эшләре турында сөйли. Йомгаклау презентациясе шәһәребезнең Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханәсендә үткәрелә. Анда шәһәр электр транспорты генераль директор урынбасары, шәһәребез язучылары, китапханәчеләр, укучылар, укытучылар, тәрбиячеләр катнаша. Язучылар, укытучылар һәм башка катнашучылар, видеоязманы карап, үзләренең уңай фикерләрен әйтә. Язучыларның ”Кама таңнары” әдәби берләшмәсе тарафыннан, берләшмә тарихында әлеге эшнең беренче генә булуы билгеләнә, мондый чараларны ешрак оештырырга кирәклегенә басым ясала. Эшләренә уңай бәя бирүләрен күреп, укучылар яңа проектлар үтәргә канатланалар.

## ФӘТТАХОВА ИЛСӨЯ ИЛЬҺАМ КЫЗЫ - ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ 13 НЧЕ ГИМНАЗИЯ-ИНТЕРНАТНЫҢ ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИОН КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ.



Ул 31 ел буе балаларга туган телебезнең нечкәлекләрен аңлатучы, аларда милли хис – татар милләтеннән булулары белән горурлану хисе, фикер йөртергә сәләтле, аек акыллы, төрле хәлләрдә дә югалып калмый

торган толерант шәхес тәрбияләүгә омтылучы, үз язмышын мәктәп, балаларга бәйләве белән чиксез бәхетле шәхес. Аның бөтен гомере киләчәк өчен лаеклы алмаш үстерүгә багышланган. Замана үзгәрә, аның белән бергә укыту системасы да катлаулана. Шуңа күрә дәресләрне яңа технологияләр, информацион белем бирү ресурсларын кулланып, заманча үткәрергә омтыла, чөнки бу дәрестә көтелгән нәтиҗәгә ирешергә ярдәм итә. Моның өчен, укытуның төрле алым-ысулларын, формаларын куллана. Хәзерге заман укытучысы беркайчан да ирешелгәннәргә генә канәгатьләнеп калырга тиеш түгел, ул һәрвакыт алга карарга, заман белән бер сафта барып, гел эзләнеп яшәргә тиеш. Илсөя Илһам кызы да үзен шушы кыйблага туры калучы мөгаллим дип саный, һөнәри бәйгеләрдә, конференцияләрдә һәрдаим катнашып килә, призлы урыннарга лаек була. (“Ел укытучысы-2012”, “Туган тел” татар теле укытучыларының Бөтенроссия мастер-класс бәйгесе, “Иң яхшы укытучы 2011, 2012, 2014”, ПНПО-2016) Төрле эшлекле киңәшмәләрдә үзенең тәҗрибәсе белән уртаклашып, эчтәлекле чыгышлар ясый.

Шушы еллар дәвамында педагог укучыларының шәһәр һәм республикакүләм олимпиадаларда, төрле иҗади бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннарга лаек булуларын үз хезмәтенең нәтиҗәсе дип кабул итә.

**Олимпиада нәтиҗәләре**

| **2014-2015** | | **2015-2016** | | **2016-2017** | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Укучының ФИО** | **Нәтиҗә** | **Укучының ФИО** | **Нәтиҗә** | **Укучының ФИО** | **Нәтиҗә** |
| Мәхмүтова Энҗе | призер | Гобәйдуллина Айгөл | җиңүче | Мөхәмәдиева Алия | призер |
| Вәлиева Зөһрә (татар теле) | призер | Гобәйдуллина Айгөл | призер | Сабитова Таңсылу | призер |
| Вәлиева Зөһрә (татар әдәбияты) | призер | Сабитова Таңсылу | призер | Сабитова Таңсылу | Республика этабында призер |
| Мөхәмәтҗанова Алия | призер | Сабитова Таңсылу | Республика этабында призер | Сабитова Таңсылу | Халыкара олимпиадада катнашучы |
| Яруллина Гөлия | призер | | | | |
| Фәрхетдинова Әдилә | призер | | | | |

**Бәйге, конференция нәтиҗәләре**

**2014-2015-** “Илһам” яшь язучылар бәйгесе, Ягмырова А., Гаптрәшитова Ә., лауреатлар;

- Шигырь укучылар конкурсы “Җирдә тынычлык хакына”, Зиннәтуллина Л., 2 урын;

**2015-2016- “** Илһам” яшь язучылар бәйгесе, Закирова Э., лауреат;

- Шигырь укучылар конкурсы «Яттан сөйлә Тукай шигырьләрен...», Сәйфуллина З., лауреат;
- Шигырь укучылар конкурсы “Теле барның -иле бар”, Сабитова Т., лауреат;
- «Чибәркәй -2016», Сабитова Т., 2 урын;

**2016-2017-** II V республика фәнни-гамәли конференциясе «Жить, помня о корнях своих…», региональ фәнни-гамәли конференция «Динамика полиэтнических и поликонфессиональных отношений в Российской цивилизации», Миңнебаева А., 3 урын;

- Р.Вәлиев премиясенә яшь язучылар бәйгесе, Сабитова Т., 1 урын;
- Мәхмүтова Э., 1 урын;
- Халыкара конкурс “Фәнни ярышлар чемпионаты”, Миңнебаева А., 3 урын;
- “Илһам” яшь язучылар бәйгесе, Сабитова Т., Мәхмүтова Э., лауреатлар;
- “Көйле, моңлы татар җыры-2017”, ансамбль, 2 урын.

Фәттахова Илсөя Илһам кызы балаларны укыту һәм тәрбияләүгә керткән зур өлеше, күпъеллык намуслы хезмәте өчен, күпсанлы мактау грамоталары белән бүләкләнгән мөхтәрәм укытучы.

## МИФТАХОВА ЭЛЬМИРА ФЛҮР КЫЗЫ – ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ 14 НЧЕ ЛИЦЕЙ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ.



Иҗади шәхес тәрбияләү - укытучының педагогик эшчәнлегенең бер юнәлеше. Укучыларының район, республика, рәсәй күләмендә үткәрелгән төрле чараларда катнашып, үрләр яулавы әлеге эшнең нәтиҗәсе булып тора. (Республикакүләм “Яшьләр фәнни эзләнүдә” фәнни-тикшеренү конференциясе, Чаллы, 2015, II дәрәҗә Диплом; Галим-мәгърифәтче И.Хәлфин исемендәге XII республикакүләм фәнни-тикшеренү конференциясе, Казан, 2016, 2017, III дәрәҗә Диплом; С.С. Молодцов исемендәге XV ачык республикакүләм фәнни-тикшеренү конференциясе, Түбән Кама, 2017, III дәрәҗә Диплом; “Туган телем – серле тел” республикакүләм шигырь сөйләүчеләр бәйгесе, Түбән Кама, 2014 нче ел - 2 җиңүче, 2015 нче ел – 3 җиңүче, 2017 нче ел – 3 җиңүче).

Ел саен Э.Ф. Мифтахова укучылары татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадаларда җиңүче булалар (2013-2014 нче уку елы, татар әдәбияты, 5 нче сыйныф, җиңүче; татар теле 5 нче сыйныф, призер; 2014-2015 нче уку елы татар теле, 7 нче сыйныф, призер; 2015-2016 нчы уку елы, татар теле 7 нче сыйныф, җиңүче; 5 нче сыйныф, татар теле, призер).

Эльмира Флур кызы - тынгы белмәс педагог. Укытучы үзенең һөнәри осталыгын арттыру өстендә даими эшли, конференция, семинар-практикум, вебинарларда катнаша. Республикакүләм “21 гасыр укытучысы остаханәсе” фәнни-тикшеренү конференциясендә катнашып II дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде. “Гамил Афзал укулары” III, IV Республикакүләм фәнни-тикшеренү конференцияләрендә катнашып II, III дәрәҗә Дипломнарына лаек булды. Укытучының Республика күләмендә төрле җыентыкларда мәкаләләре даими басыла. “Гамил Афзал укулары-2015” IV республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары” (Казан: КФУ, 2015. – 292 б.) җыентыгында “Татар телен һәм әдәбиятын укытуда яңа технологияләр” статьясы, “Без тумыштан туган телгә гашыйк, туган җиргә гашыйк күптәннән” V республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Минзәлә, 2017. – 552 б.) җыентыгында “Әхлакый –экологик тәрбия – күңел хәзинәсе” исемле чыгышы үрнәге дөнья күрде.

Эльмира Флүр кызы һөнәри һәм педагогик конкурсларда катнашып, югары урыннарга ия була. Шәһәр башлыгы грантының “Милли мәгариф һәм мәдәниятне үстерү” номинациясендә II урынга лаек булды (2013 нче ел), “Образование” өстенлекле милли проектның “Яхшы укытучы” бәйгесенең Татарстан Республикасы күләмендә җиңүче (2015 нче ел), “Укытучы-мастер” республикакүләм гранты иясе (2016 нчы ел).

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДАЛАРГА ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА РЕСУРС ҮЗӘКЛӘРЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Фәттахова Илсөя Илһам кызы,*** *13 нче гимназия-интернатның югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



*Фәттахова И.И.*

Сәләтле балаларны олимпиадаларга әзерләү укытучыдан системалы эш таләп итә. Шуңа күрә әлеге эшне башлангыч сыйныфлардан ук башларга кирәк. Барыбызга да мәгълүм булганча, татар теленнән олимпиадага әзерләнү өчен үрнәк биремнәр, ярдәмлекләр бик аз. Шуны истә тотып, быелгы уку елында шәһәребезнең мәгариф идарәсе, билгеле бер юнәлештә эшчәнлек алып бару өчен, берничә белем бирү оешмасы кысаларында (Б.Урманче исемендәге 2 нче гимназия, 5 нче мәктәп, 13 нче гимназия-интернат) балаларны татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадага

әзерләү буенча ресурс үзәкләр оештырды. Әлеге үзәкләрнең *төп максаты*- татар сыйныфларында, рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар һәм рус төркемнәрендә укучыларның татар теле һәм әдәбиятыннан белем дәрәҗәләрен, сөйләм күнекмәләрен тикшереп, сәләтле балаларны ачыклау; укучыларның белемнәрен системага салырга ярдәм итү, шәһәр һәм республика олимпиадаларына мөстәкыйль әзерләнергә юнәлеш бирү. Монда тупланган олимпиада сораулары, биремнәре аша, укучыларда татар теленнән олимпиада хакында гомуми күзаллау булдыру, булган белемнәрне камилләштерү, киләсе бәйгеләргә әзерлек юнәлешен билгеләргә ярдәм итү күздә тотыла.

Ресурс үзәкләрнең планнары алдан ук төзелеп, муниципаль дәрәҗәдә расланды, анда йөриячәк укытуыларның исемлекләре төзелде, ягъни иҗади төркемнәр оештырылды. План буенча һәр үзәктә 10 утырыш билгеләнде, чыгыш ясаучы мәктәпләр күрсәтелде. Һәр эшлекле киңәшмәдә график буенча җаваплы уку оешмасы әгъзаларының чыгышлары тыңланды. Теориягә нигезләнгән чыгышлар, әлбәттә, гамәли күнегүләр, осталык дәресләре белән үрелеп барды. Чыгыш ясаучы укытучылар балаларны олимпиадага әзерләгәндә, аларның сүз байлыгын үстерүгә, телдән һәм язмача аралашуга, үз фикерләрен төгәл, ачык белдерә алуга игътибар бирергә кирәклеген ассызыкладылар. Тәкъдим ителгән олимпиада биремнәрен башлангыч һәм урта сыйныфларда эшләүче татар теле укытучылары олимпиадага әзерләү өчен файдалана алачаклар. Хәзер, әйдәгез, һәр ресурс үзәге эшчәнлегенә җентекләбрәк тукталыйк.

Татар сыйныфларында укытучылар белән эш юнәлешен оештыру Б.Урманче исемендәге 2 нче гимназиягә йөкләнде. Анда барлыгы 9 белем бирү оешмасы кертелде, утырышларга даими рәвештә 10 укытучы йөрде, аларның һәрберсе тирән эчтәлекле чыгышлар ясады. Замана таләпләренә нигезләнеп, сәләтле балалар белән эшләү,татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадага әзерләү юлларын эзләү тәҗрибәсе белән Б.Урманче исемендәге 2 нче гимназия укытучылары Минһаҗева А.Ф., Зарипова Ә.Г., Хаҗиева З.Г. уртаклаштылар.Беренче утырышларда татар теленнән һәм әдәбиятыннан мәктәп этабы биремнәре каралды. (Хаҗиева З.Г., Шәймөхәммәтова Ф.М., Гәрәева Г.Р., Хәйруллина Г.Р.) Шулай ук 7-8 сыйныфларда республика этабы биремнәре (Сөнгатуллина Л.М., Насырова М.С.), 9-11 сыйныфларда булган биремнәр буенча (Зарипова Ә.Г., Сөнгатуллина Л.М., Гарипова Л.Р.) чыгышлар тыңланды. Олимпиадаларда комиссия рәисе булган Гарипова Л.Р. психологик һәм физиологик яктан киңәшләрен бирде, тәкъдимнәрен җиткерде. Утырышларның икенче яртысында әлеге укытучылар “Сәләтле балалар белән эшне оештыру методикасы”дип исемләнгән осталык дәресләре күрсәттеләр.

Рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең *татар төркемнәрендә* укучы балаларны татар теле һәм әдәбият буенча олимпиадаларга хәзерләү өчен ресурс үзәк итеп шәһәребезнең 5 нче мәктәп базасы сайланды. Айга бер тапкыр җыелып,мәктәп укытучылары үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, борчыган сорауларына җаваплар эзләделәр. Исемлеккә кертелгән 38 укытучы да киңәшмәләргә бик теләп йөрде, барлыгы 14 чыгыш тыңланды. Беренче утырыш оештыру эшләре белән башланып китте. Анда Шәйхиева Н.С. ресурс үзәгенең эш планы, максаты, бурычлары белән таныштырды, утырышларны үткәрү графигы таратылды. Кирәкле темалар сайланды, чыгыш ясарга тиешле укытучылар билгеләнде. Шушы ук утырышта 5 нче мәктәп укытучысы Ильина З.Е. “Сәләтле укучыларны сайлап алу методикасы” темасына чыгыш ясады. Ул үз чыгышында күренекле педагогларның сәләтле укучыларны сайлап алу турындагы фикерләре белән таныштырды, үз мәктәбенең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты. Сәләтле балалар белән эшләүнең төрле юлларын башка укытучыларның чыгышларыннан да күзәттек. (Яруллина Г.С., Ганиева Р.Ф, Хадиева С.А.) Шулай ук әдәбият теориясенә кагылышлы биремнәргә багышланган файдалы, кирәкле мәгълүматлар җиткерә, олимпиадаларга ярдәм итә торган эчтәлекле чыгышлар тәкъдим ителде (Галиева Г.Ф., Харисова Ч.С., Осипова Г.Т.). Татар теле буенча үткәрелгән мәктәп һәм шәһәркүләм олимпиада биремнәренә тулы күзәтү ясалды. (Закирова И.Г., Хәйруллина Ф.А., Харисова Ч.С.). Ә инде ничә еллар дәвамында төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда җиңүче-призерлар әзерләүче тәҗрибәле остазларның күрсәтмәләре (Масалимова М.М.,

Исмәгыйлева И.Г., Фәттахова И.И., Якупова В.Б., Шәйхиева Н.С.) яшь белгечләр өчен генә түгел, урта буын укытучыларына да зур ярдәм булды. Күп еллар мәгариф системасында хезмәт куючы, балаларга төпле белемнәр бирүче 20нче мәктәп укытучысы Д.М. Константинованың ”Рамон Кампао методикасы буенча сүз байлыгын тиз үзләштерү”, 24нче лицей укытучысы З.М. Мөхетдинованың ”Әдәбият дәресләрендә штурм методын куллану” кебек кызыклы чыгышлары да хезмәттәшләребез күңеленә хуш килде. Шуны да искәртеп китик: үткәрелгән осталык дәресләре дә бик урынлы булды. (Сәйфетдинова Ф.Х., Афанасьева Л.С.)

Өченче ресурс үзәге эшчәнлеге 13 нче гимназия-интернаты базасы кысаларында оештырылды. Анда рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең *рус төркемнәрендә* эшләүчеләр җыелды. Бүгенге көндә татар теле укытучылары рус төркемнәрендә укучы балаларны олимпиадага әзерләү өчен махсус биремнәр җыентыгына ихтыяҗ тоялар. Шуларны исәпкә алып, шәһәребез укытучылары үткән елгы олимпиада нәтиҗәләренә анализ ясап, быелгы уку елында булачак яңалыклар, татар теле буенча үткәреләчәк олимпиадалар, анда булырга мөмкин булган биремнәр белән таныштырдылар, үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алдылар, үзара фикер алыштылар. Бу эшлекле киңәшмәләрдә барлыгы 19 чыгыш тыңланды. Аларда алдагы елларда муниципаль һәм республика дәрәҗәсендә үткәрелгән олимпиада биремнәренең типлары исәпкә алынган иде: сүзләрнең транскрипциясен язу һәм укучыларның татар сүзләренең дөрес әйтелешен үзләштерүләрен тикшерүгә юнәлтелгән биремнәр (Вафина Л.Р., Долгова Г.М., Усманова С.М.); лексик-грамматик биремнәр: исемнәрнең килеш һәм тартым кушымчалары, җөмләдә сүз тәртибе, җөмлә чикләрен билгеләү һәм тыныш билгеләренең тиешлесен куя белү, хикәя фигыльнең заман формалары һәм зат-сан кушымчаларын куллану, сүзләрнең синонимнарын, антонимнарын табу һ.б (Ильина З.Е., Нуриева Э.Г., Никитина А.Е.); укучыларның бер телдән икенче телгә тәрҗемә итә белү күнекмәләрен тикшерүгә корылган биремнәр (Бәдретдинова Л.М., Хәйруллина Г.М.); коммуникатив максат белән бирелгән биремнәр (Фәттахова И.И., Вәлиуллина Л.Д., Камалиева Д.В.); сөйләм һәм аралашу күнекмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән: сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү (Әхмәтова М.И., Латыйпова Р.Х., Әминова Э.З., Егорова Р.Х.); иҗади биремнәр: билгеле бер темага хикәя төзү, мини сочинение язу, татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен куллану (Шәрәпова Н.Н., Хәйретдинова Г.Ф., Хуҗанбирдиева Ч.Т.) Йомгаклау сүзе белән рус төркемнәрендә эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларының шәһәр методберләшмәсе җитәкчесе Насыйбуллина Д.Ф. чыгыш ясады. Ул агымдагы уку елында муниципаль этапта 29 җиңүче-призер булуын, республика турына шуларның бары 3 се генә үтүен һәм призерлар исеменә лаек булуын җиткерде, бу безнең өчен куанычлы нәтиҗәләр түгеллеген ассызыклады.

Укучыларны олимпиадага әзерләү, әлбәттә, укытучылардан күп әзерлек һәм балалар белән индивидуаль эш алып баруны таләп итә. Бүгенге көн балалары арасында үтә сәләтлеләре байтак, безнең бурыч – аларның әлеге табигать тарафыннан бирелгән сәләтләрен вакытында ачыклау,үстерү өчен җирлек һәм уңай шартлар тудыру, ихтыяҗларын төрле яктан канәгатьләндерү. Шул вакытта гына көтелгән нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ МӘКТӘПЛӘРДӘ УКУЧЫЛАРНЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДАГА ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

***Шәймөхәммәтова Фәнзилә Мирзанур кызы,***
*Татарстан Республикасы Түбән Кама*
*муниципаль районы Бакый Урманче исемендәге*
*2 нче гимназиянең югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


*Шәймөхәммәтова Ф.М.*

Татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерлек укучыдан һәм мөгаллимнән шактый күп вакыт һәм көч сарыф итүне сорый. Сәләтле бала белән олимпиадага әзерлек эше уку елы башыннан ук даими һәм системалы алып барылырга тиеш.

Татар әдәбиятыннан олимпиада структурасы түбәндәгедән гыйбарәт:

I Әдәбият теориясенә караган биремнәр;

II Әдәби чорга һәм әдәби иҗатка кагылышлы биремнәр;

III Иҗади эш.

Тәкъдим ителгән биремнәр укучыларның теоретик белемнәрен; әдәби барышны, аерым бер әдипнең иҗат үзенчәлекләрен бәяләү, әдәби әсәр белән эшләү мөмкинлекләрен; әсәргә яки чорга шәхси фикерен, мөнәсәбәтен белдерә алу сәләтен ачыклау максатларын күздә тотып эшләнә. Иң беренче чиратта, әдәби әсәрләрне кабат укып чыгу, тәнкыйди материаллар белән танышу, алар турында шәхсән уйлану киңәш ителә, чөнки җавапларда дәреслек материалын гына күчереп кую үзен акламый, әзерлек дәрәҗәсен дә арттырмый. Иң мөһиме: җаваплар укучының, дәреслек материалына һәм тәнкыйди язмаларга таянып, үз шәхси бәясен, фикерләү дәрәҗәсен чагылдырырга тиеш. Җаваплар озын булмыйча, төгәл һәм тәмамланган фикерләрдән торса яхшы. Биремнәрдәге һәр сорауга төгәл, дәлилле җавап таләп ителә.

Беренче төркем сорау укучының теоретик төшенчәләрне аңлау дәрәҗәсен ачыклауны күздә тота. Укучы теге яки бу теоретик төшенчәгә коры билгеләмәне генә язып куярга түгел, ә бәлки, аның төп сыйфатларын күрсәтелгән әсәр нигезендә дәлилли алырга тиеш.

Икенче төркем сорау билгеләнгән әдип иҗатына яки бер әсәргә бәя бирүне күздә тота, төгәллекне, теоретик материалны белеп, дөрес куллануны сорап тора. Җавап эчтәлек сөйләүгә кайтып калмасын, авторның әйтергә теләгән фикерен, үз караш-мөнәсәбәтеңне ачыклау юнәлешендә булсын. Һәр фикер конкрет фактлар, әсәрдән мисаллар, фрагментлар белән ныгытылсын. Әдәби әсәрнең поэтик үзенчәлекләрен, язучының стилен, төп иҗади сыйфатларын бәяләү шул дәвердәге әдәби-тарихи контекст белән бәйләп алып барылса яхшы.

Аерым бер чорга бәя бирүне күздә тоткан сорауга җавап бирү барышында чорның төп тарихи һәм иҗтимагый вакыйгаларын, аларның шул чор сәнгатенә йогынтысын ассызыклап, күрсәтелгән вакыт аралыгында әдәбиятның төп сыйфатларын, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, үзенчәлекләрен аерып чыгару, өстенлек иткән иҗат юнәлешен, агымнарын, әдәби жанрларны, күтәрелгән тема-проблемаларны ачыклау, дәвернең сүз осталарын санап китү, аларның чор әдәбиятында тоткан урынын билгеләү сорала. Кайбер биремнәрдә ул, киңрәк характерда булып, укучының хәзерге әдәби процесс белән танышлыгын, әдәбияттан мәгълүматын, шәхси мөнәсәбәтен, логик фикерләү дәрәҗәсен, иҗади мөмкинлекләрен, дөньяви эрудициясен дә ачыклауны күздә тота. Җавапта күрсәтелгән әсәргә һәм чорга үз бәяңне бирү мөһим.

Әдәби әсәргә анализ ясауны таләп иткән сорау укучыларның әдәби әсәргә анализ ясау дәрәҗәсен, теоретик белемнәрен ачыклау максатыннан анализга һәр әдәби төрдән бер әсәр тәкъдим ителә. Эпик әсәргә анализ барышында төп теоретик төшенчәләр аша автор фикерен, сюжет сызыкларын, каршылыкны, тема-проблеманы аерып чыгару, әсәргә үз карашыңны

һәм мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрнең актуальлеген билгеләү сорала; лирик әсәрләргә анализда төп лирик мотивларны аерып чыгару, лирик геройның хис-кичерешен, аның сәбәпләрен ачыклау таләп ителә; драма әсәрләренә анализның төп эчке һәм тышкы каршылыкларны ачыклау, образларга характеристика бирү, автор фикерен-идеясен ачыклау юнәлешендә алып барылуы мөһим.

Әдәби төрләргә анализ ясаганда нәрсәләрне истә тотып эш итәргә кирәк.

Лирик әсәрнең нигезендә хис-кичереш ята. Аларны анализлауның иң киң таралган юлы - «автор артыннан бару». Ул строфадан строфага лирик геройның хис-кичереш көчешен һәм аның сәбәпләрен, поэтик образлар, яки башка элементлар аша хиснең дәрәҗәсен билгеләү, юану өлешен ачыклау, шигырьдән алган тәэсирне ассызыклау юнәлешендә алып барыла. Моннан тыш жанры, ритм-рифмалар, символ-метафоралар аша үткәрелгән мәгънә, автор фикере, темасы күзәтелә. Шигырьнең темасы хиснең сәбәбе белән бәйле була.

Эпик төргә исә вакыйгалылык хас. Шуңа да эпик әсәргә анализ сюжетны күзәтүдән башлана һәм төп сюжет сызыкларын билгеләү, андагы каршылык үсеше аша сюжет элементларын ачыклау, образларга характеристика бирү юнәлешендә алып барыла. Төп каршылыкны ачыклау теманы табарга ярдәм итә, аны тудыручы сәбәпләр еш кына проблема булып төгәлләнә. Эпик әсәрдә тема, үз чиратында, идея белән бәйләнештә була. Проблема дәрәҗәсендә куелган сорауларга автор идея катламында җавап таба. Биредә теге яки бу мәсьәләгә автор мөнәсәбәтен, әдипнең позициясен, бәясен ачыклау мөһим. Геройларга һәм әсәрнең композициясенә бәя бирү барышында геройларның портретына, пейзажга, вакыйгаларның бару урынына, психологизмга - халәт, эчке дөнья, кәеф үзгәрешенә һ.б. әйберләр дөньясына игътибар итү сорала. Алар аркылы язучының иҗади осталыгы, язу стиле билгеләнә һәм әсәргә укучының үз шәхси мөнәсәбәте, бәясе урын ала.

Драма әсәрләренәан ализ тышкы һәм эчке каршылыкларны аерып алудан башлана. Герой белән герой, герой белән тирәлек, герой белән җәмгыять арасындагы тышкы яки төп герой күңелендә барган эчке каршылыкларда җәмгыятькә хас проблемалар калкытып куела. Төп каршылыкның сәбәбе еш кына проблема булып төгәлләнә. Конфликт барлык персонажларны хәрәкәткә китерә, аларның характерын ачарга ярдәм итә. Шуңа да анализ барышында конфликт үсешен һәм герой характерларын янәшә куеп тикшерү отышлы санала. Драма әсәренә дә сюжетлылык хас. Конфликтның үсеш-үзгәреш тарихын күзәтү сюжет элементларын билгеләргә ярдәм итә. Драма әсәрендә автор фикере, идея исә персонажлар сөйләме, эш-гамәлләре аркылы үткәрелә.

Олимпиадага әзерлек барышында чәчмә, тезмә, драма әсәрләренә анализ ясау үрнәкләрен өйрәнергә кирәк. Алга таба анализ үрнәкләре күрсәтелә:

А. Яхин методикасы буенча әсәрләргә анализ.

**I А. Яхин методикасы буенча чәчмә әсәрләргә анализ**

1. Вакыйгаларны барлау.
2. Вакыйгаларның охшашларын гомумиләштереп, ике өлешкә калдыру.
3. Һәр өлешкә анализ ясау.
4. Өлешләр арасында бәйләнеш эзләү (каршылык).
5. Тема, проблема, идеясен ачыклау.

**II А.Яхин методикасы буенча тезмә әсәрләргә анализ**

1. Шигырьнең төзелешен тикшерү.
2. Шигырьне ике өлешкә бүлү.
3. Һәр өлешне анализлау.
4. Өлешләр арасында бәйләнеш табу.
5.Хисне табу. Хиснең сәбәбе, дәрәҗәсе юануы табыла.

**III А.Яхин методикасы буенча драма әсәрләргә анализ**

1. Әсәрдә каршылык табу.
2. Әсәрне ике өлешкә бүлү.
3. Һәр өлешкә анализ ясау (Һәр өлештән ярдәмче конфликтларны табу).
4. Өлешләр арасында бәйләнеш табу.

Д. Заһидуллина буенча анализ ясау үрнәкләре.

***Чәчмә әсәр анализлау планы***

1. Әсәрнең язылу вакыты, тарихы (билгеле һәм кирәк булса).
2. Төп әдәби образлар системасы. Аларны сыйфатлау.
3. Сюжет бирелеше. Конфликт.
4. Әсәрнең тема, проблема, идеясе.
5. Сурәтләнгән дөнья ( пейзаж, портрет, әйләнә-тирә дөньяны тасвирлау).
6. Әсәрнең композициясе.
7. Әсәрнең теле (автор сөйләме, хикәяләү, сурәтләү, персонажлар сөйләме, тел-сурәтләү үзенчәлекләре).
8. Жанры.
9. Әсәрнең язучы иҗатында тоткан урыны.
10. Татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы.

***Лирик шигырь анализлау планы.***

1. Язылу вакыты. Реаль-биографик һәм фактологик аңлатмалар (билгеле һәм кирәк булса).
2. Жанры.
3. Лирик геройга бәя. Аның сурәтләнгәннәргә мөнәсәбәте, кичереше, фикере.
4. Тема, төп эчтәлек.
5. Хисләр бирелеше, аларның гәүдәләнеше, үсеш-үзгәреше.
6. Төп образлар, аларның әһәмияте, яңалыгы.
7. Сөйләм үзенчәлекләре, сурәтләү чаралары.
8. Әсәрнең төзелеше.
9. Шигырь төзелеше ягыннан бәя. Ритм һәм рифма.

***Драма әсәрен анализлау планы***

1.Әсәрнең язылу вакыты, тарихы (билгеле һәм кирәк булса).
2. Төп тышкы һәм эчке каршылыклар. Конфликт бирелеше.
3. Сюжет бирелеше һәм сюжет элементлары.
4. Әсәрнең тема, проблема, идеясе.
5. Образлар системасы.
6. Әсәрнең теле (автор сөйләме, хикәяләү, сурәтләү, персонажлар сөйләме, тел-сурәтләү үзенчәлекләре).
7. Жанры.
8. Әсәрнең язучы иҗатында тоткан урыны.
9. Татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы.

Олимпиадада өченче бирем - иҗади эш. Иҗади биремгә ничек әзерләнергә.

Әдәбият олимпиадасы инша язудан башка уза алмый, әлбәттә. Еш кына аны соңгы бирем итеп куялар. Инша я исә хикәя язу әдәбият белән таныш булган укучы өчен бер нинди кыенлык та тудырырга тиеш түгел. Теория, тарих буенча булган сораулар нинди дер шик тудыра алсалар, язу гомумән икенче юнәлешкә карый. Димәк, укучының нәкъ шушы биремнән югары балл җыярга мөмкинлеге бар. Ә хәзер язган вакытта нәрсәләргә игътибар бирергә кирәк икән, шуларны карап үтик.

1. Әдәби төр, жанр таләпләренә буйсындырып язарга. Мәсәлән, хикәя жанры бирелгәндә, аның кечкенә күләмле, образлар санының аз булуын һәм конфликтлы сюжетка корылуын истә тотарга кирәк.
2. Язган вакытта грамматик, стилистик хаталарны булдырмаска. Җөмләләр төзек, эзлекле һәм мәгънә ягыннан дөрес булырга тиешләр.
3. Вакыт турында да истән чыгарырга ярамый. Бу бирем соңгы булганлыктан, сорауларга җавап биргәннән соң язу өчен вакыт бик аз калырга мөмкин, шуңа күрә фикер эзлеклелеген саклап тәмамларга кирәк.
4. Язманың кереш, төп һәм йомгак өлешләре булырга тиеш. Мондый бүленеш укучының әсәр төзелеше белән яхшы таныш булуын күрсәтә.
5. Бирелгән тема буенча гына язарга кирәк.

6. Һәр бер җөмләдә ниндидер тирән мәгънә, фикер ятсын. “Су кушу” бары тик кирәкмәгән сүзләр артуына гына китерә.
7. Образлар тудырганда аларның чын барлык белән якын килүләренә дә игътибар итәргә кирәк.
8. Иҗади эштә күтәрелгән проблемаларның башкалар өчен дә кызыклы, мөһим булуы зарур.
9. Иҗат эшенең әдәбилексикага кергән сүзләр белән язылган булуы сорала. Монда укучының сүзлек составы никадәр бай икәне күренә.
10. Бер төрле сүзләрне гел кулланмас өчен синонимнарга мөрәҗәгать итәргә кирәк.
11. Әлбәттә, тел-сурәтләү чаралары әсәрне тагын да матурлый, бизи.
12. Язып бетергәч, эшне башта хаталар, аннары мәгънә ягыннан тагын бер кат тикшереп чыгарга кирәк.

Кулланылган әдәбият:


1. Гафиятуллина Н.М. “Олимпиадага әзерләнү өчен ярдәмлек: татар әдәбияты”/Н.М. Гафиятуллина. - Казан:Казан дәүләт университеты, 2004 – 52 б.
2. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма./ Д.Ф. Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005 – 99 б.
3. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма / Ф.Хатипов. – Казан: Раннур, 2002. – 351 б.


## СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ – ҮЗЕ БЕР СӘЛӘТ


***Насыйрова Миләүшә Сәлмән кызы,***
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы МБББУ “14 нче лицей” ның беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*




*Насыйрова М.С.*

Кешелек дөньясы яңа меңьеллыкта – XXI гасырда яши. Без, татарлар, яңа гасырны кешелек үсешенә зур өлеш керткән халык буларак каршыладык һәм киләчәккә зур ышаныч белән карыйбыз. Шуның өчен дә хәзерге чорда дөнья күләм мәсьәләләр хакында фикер йөртерлек шәхес тәрбияләү аеруча әһәмиятле. Төрле телдәге фәнни чыганаклардан мәгълүматлар туплап, үз карашын берничә телдә аңлатып бирә алырлык киләчәк кешесен тәрбияләү төп бурыч булып тора. Хәзерге заман мәктәбе үзенең үсешендә катлаулы чор кичерә. Заман таләбе – баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес итеп тәрбияләү. Белгәнебезчә, укыту өлкәсендә сәләтле балаларны табу һәм аларның эшчәнлеген үстерү – хәзерге көн таләбе. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз.

Сәләтле бала нинди була соң ул? Югары интеллектлы, нинди дә булса эшчәнлектә уңышларга ирешүче, иҗатка тартылучы бала – сәләтле бала була да инде. Шундый укучылар белән яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен, әлбәттә, әзерлекне, эшчәнлекне системалы алып барырга кирәк.

Сәләтле балалар белән эшләү безнең мәктәп эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе булып тора. Сәләтле балалар һәр мәктәптә дә бар. Без аларны һәрвакыт игътибар үзәгендә тотабыз һәм аларның бу сыйфатларын тагын да үстерергә тырышабыз.

Галимнәр сәләтсез балалар юк, һәркемнең нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышы була диләр, ә безнең – укытучыларның бурычы – баланың сәләтен ачыклау, ихтыяҗын төрле яктан канәгатьләндерү, сәләтен үстерү. Бу уңайдан татар теле һәм әдәбияты дәресләре – укучылар эшчәнлеген активлаштыру, иҗади фикерләү өчен бик тә уңайлы җирлек.

Татар теле укытучысы буларак, мөһим бурычларымның берсе – укучыларны мөстәкыйль рәвештә иҗади фикер йөртергә һәм нәтиҗә ясарга өйрәтү, укучыларның эзләнү, тикшеренү һәм иҗади фикерләү эшчәнлеген активлаштыру, сәләтле балалар белән эшләү.

Сәләтле балалар барлыгын ачыклау гына татар теле укытуның нәтиҗәлелеген күтәрми. Һәр баланың үзенә генә хас сыйфаты бар. Мин исә, сөйләү күәсе көчле булган, татар әдәби телендә дөрес, ачык сөйләшүче, фикер йөртүче, зиһенле балаларны фәнни-гамәли конференцияләргә, ә татар теле грамматикасы буенча тырыш, ныклы белеме булганны, ләкин тыныч холыклы, күзгә артык ташланмый торган укучыларны фән олимпиадаларына тартырга тырышам.

Шушы юнәлештә сәләте булган балалар белән эшләгәндә, укучылар алдына мондый бурычларны гамәлгә ашыруларын максат итеп куям:

а) программа материалын бик яхшы белү;

ә) өстәмә чыганаклардан мәгълүмат алу; әдәби әсәр укыту;

б) бөтен төр анализ үрнәкләрен белү;

в) халкыбызның үткәне, бүгенгесе турындагы материалларны өйрәнү, вакытлы матбугат белән кызыксыну, радио, телевидениедән татарча тапшыруларны карап бару;

г) фикерләү сәләтен үстерү;

д) мөстәкыйль эшләргә өйрәнү.

Сәләтле балалар белән эшләү нәтиҗәле булганда гына һәр ике як өчен кызыклы, мавыктыргыч. Эш барышында көтелгән нәтиҗәгә ирешмичә дә калына. Шуңа күрә укытучы буларак, укучыларымны психологик яктан бәйге алдыннан әзерләп куярга тырышам. Күбрәк балаларга мөстәкыйльлеккә ирешергә, үзе өчен җавап бирергә, чаялык күрсәтү кирәклегенә басым ясыйм.

Бала никадәр сәләтле булмасын, олимпиадага дәрестән соң гына әзерләнеп югары нәтиҗәгә ирешеп булмый. Шуңа күрә мин бу эшне түбән сыйныфтан ук башлыйм. Иң элек балаларда фәнгә карата кызыксыну уяту зарур. Моңа төрле кызыклы ребуслар, шарадалар, кроссвордлар эшләү ярдәм итә. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланам. Укытучы белән укучы арасындагы әңгәмәләр, фикер алышулар, тест биремнәрен үтәү, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Сүзлекләр белән эшләүгә аеруча игътибар итәм. Тел галимнәренең хезмәтләре белән танышу да уңай нәтиҗә бирә, балаларда кызыксыну уята. Җирле матбугат язмаларын күзәтү, андагы стиль хаталарын төзәтү, бүгенге шигъриятне күзәтү балаларның сөйләм байлыгын үстерә, аларны образлы фикер йөртүгә этәрә. Мин беркайчан да кагыйдәләрне ятлату белән шөгыльләнмим. Төп максатым – укучының теге яки бу тел күренешен аңлап үзләштерүе һәм төрле авырлыктагы күнегүләрне үти алуы.

Дәрестән соң үткәрелә торган түгәрәкләр дә олимпиадага әзерлекнең бер төре. Моннан тыш идивидуаль эшне өйгә биреп җибәрәбез, гаиләдә ата-аналар белән берлектә эшлиләр. Шулай ук балалар үзләре дә кызыклы биремнәрне интернеттан табып, сыйныфта эшләү өчен тәкъдим итәләр. Сәләтле балаларга дәрес материалы кызык булмаска мөмкин, шуңа күрә авыррак күнегүләр аларны кызыксындыра һәм активлаштыра. Дәресләрдә бу укучыларга, темаларны үткән вакытта, өстәмә чыганаклардан файдаланырга, иҗади эзләнергә кушам.

Сәләтле балалар күп, ләкин һәркайсы белән иркенләп утырып эшләргә мөмкинлек тә, вакыт галиҗәнәпләре дә җитми. Бер уку елына фәнни-гамәли конференцияләргә күп булса, 2-3 эш, конкурсларга 5-6 укучы, олимпиадаларга 4-5 укучы әзерләнә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, укучылар белән индивидуаль эшләү өчен:

- алар белән һәрвакыт бәйләнештә, элемтәдә булырга;
- хезмәтеңне теләп, яратып башкарырга;
- уңай энергия ала һәм бирә белергә;
- тормышка ышаныч белән карарга өйрәнү мөһим.

Балык тотарга һәрвакыт ике балыкчы йөргән. Көн саен боларның юлына бер ач кеше чыга икән. Балыкчыларның берсе һәрвакыт балыгының бер өлешен ач кешегә биргән. Икенчесе

исә – юк. Бу хәл бер көн кабатланган, икенче көн. Өченче көнне бер балык та бирмәүче балыкчы бу ач кешегә кармак алып килеп биргән. Ач кеше үз тамагын үзе туйдыра башлаган.

Балаларның сәләтләрен ачу өчен кулланган чаралар, яңа укыту технологияләре, ысуллар әнә шул икенче балыкчыга охшаган, укучыга материалны әзер килеш түгел, ә эзләнү аша бирергә кирәк – шул чакта гына балаларның сәләтләрен барлауга юл ачыла.

Бөек шәхесебез Р. Фәхретдин әйткәнчә, “Һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә сәнгать өлкәләрендә милләтенең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиеш”. Халыкның үткәнен, тарихын, сәнгатен өйрәнгән, хезмәт сөйгән, матурлыкны күрә белгән, үзара дус һәм тату мөнәсәбәттә тәрбияләнгән балаларның киләчәге өметле.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Татар теленнән гомуми белем бирү стандарты К.2008
2. Р.А. Юсупов. Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1983
3. Педагогик технологияләр турында “Мәгариф” журналларындагы материаллар (2012-2013 еллар)
4. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан, 2000.
5. Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Тәрбия - мәңгелек фәлсәфә: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен педагогикадан уку ярдәмлеге.- Казан: Мәгариф, 2001.


## СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН


***Гарипова Лилия Рәүф кызы,***

*Түбән Кама районы, Каенлы урта мәктәбенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*




*Гарипова Л.Р.*

Соңгы елларда илебездәге белем бирү оешмалары Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартын тормышка ашыру шартларында эшли. Бу исә укучылар һәм укытучылар алдына яңа бурычлар һәм яңа таләпләр куя. Стандартта күрсәтелгән шәхси, предмет һәм метапредмет нәтиҗәләренә ирешү өчен, мәгариф системасы үз эшен яңача үзгәртеп корырга тиеш.Әлеге эшне оештырганда укытучыга заманча алымнар, яңа технологияләр белән коралланырга һәм үзгәрешләр кичергән дәреслек, методик кулланмалар, электрон әсбаплар белән белем бирергә туры килә. Бүгенге укытучы үз укучылары белән дәрес кысаларында гына эшләми, бәлки төрле конференцияләрдә, конкурс һәм бәйгеләрдә дә катнаша. Шушы уңайдан республикабызда предмет олимпиадаларының киң таралуын билгеләргә кирәк.

“Олимпиада” сүзе грек теленнән алынган olumpias - “ярыш, смотр, конкурс” дигәнне аңлата.

Олимпиадада катнашкан укучылар үзләренең гомуми эрудициясен һәм логик фикерләү сәләтен күрсәтәләр. Дәресләрдә үзләштерелгән тел материалы яңа шартларда төзелгән биремнәрне үтәү барышында тагын да актуальләштерелә, ә ул исә балаларның аралашу, лингвистик һәм этнокультурага караган компетенцияләре үсешенә зур йогынты ясый.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы үткәрә торган төрле дәрәҗәдәге олимпиадалар уку-укыту һәм белем бирү эшендә үзенең лаеклы урынын тапкан. Укытучылар, ата-аналар белән бергә әлеге эшкә укучылар да бик теләп тартыла. Алар өчен олимпиада - үзенең белем дәрәҗәсенә хәзерге заман югарылыгыннан чыгып бәя бирү генә түгел, ә яңа дуслар белән танышу, аралашу урыны да.

Укучыларны фәннәр буенча олимпиадага әзерләү укытучыдан да, укучыдан да бик күп көч, сабырлык һәм тырышлык таләп итә. Анда катнашучылар арасыннан сәләтле балаларны сайлау, алар белән даими шөгыльләнү өчен дә олимпиада үткәрүнең файдасы шактый.

Олимпиадада катнашучы укучыны сәләтле бала дип әйтер идем мин. Сәләтлелек билгеләре дигәндә, беренче чиратта, кешедәге акыл үсешенең югары дәрәҗәсен күз алдында тотарга кирәк.Өйгә бирелгән эшләр белән чикләнмичә, өстәмә әдәбият белән дә танышучы балаларны аеруча сәләтле балалар рәтенә кертергә мөмкин. Әгәр дә бала сәләтле булса, ул тәкъдим ителгән мәгълүматлар белән генә канәгатьләнми. Сәләтле балаларга хас сыйфат- акыл үсешенең югары темпы.

Сәләтле бала белән эшләүнең төп максатыитеп түбәндәгеләрне әйтер идем:

– баланың сәләтен үстерү өчен шартлар тудыру;

– телне һәм әдәбиятны өйрәнүне һәрьяклы үсешкә ирешкән шәхес формалаштыруда кирәкле итә алу;

– республика, рәсәйкүләм, халыкара олимпиада-бәйгеләрдә җиңүчеләр әзерләү.

Моның өчен түбәндәге бурычларны чишәргә кирәк:

– сәләтле баланы ачыклау;

– балага үз-үзен билгеләүдә ярдәм итү;

– күп санлы метод һәм алымнар арасыннан мөстәкыйль фикерләүгә, иҗади эшчәнлеккә китерә торганнарын сайлап ала белү.

Шушы бурычларны тормышка ашыру өчен, беренче чиратта, дәрестә һәм дәрестән соң бу укучыга аерым игътибар бирергә кирәк, өстәмә эшләр, логик фикерләүгә караган биремнәр аның һәрвакыт кул астында булырга тиеш.

Көтелгән нәтиҗә:

Сәләтле баланың республика, Бөтенроссия, халыкара олимпиадаларда уңыш яулавы, һәм бу уңышларның бала киләчәктә сайлаячак һөнәр өчен кирәкле булуы.

Олимпиадаларда катнашучы сәләтле балалар бедән эш кече яшь тә үк башлана.

Башлангыч сыйныфтан ук татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынган балаларны күреп алырга кирәк. Аларның татар китабынукулары аеруча мөһим. Бу чорда укучыларга грамматик материалны яки әдәбият теориясен артык катлауландырырга кирәкми, ә бәлки баланы җәлеп итүнең, кызыксынуларына бәйлерәвештә, яңа ысулларын табу максатка ярашлы булачак. Укучылар белән класстантыш чараларга әзерләнү, иҗади эшләр башкару, балалар өчен булган газета-журналлар белән хезмәттәшлек итү яхшы нәтиҗә бирәчәк. Укучы урта сыйныфка күчкәч тә олимпиадада катнашырга тиешле укучыны төп төркемгә кушам. Инде бу вакытта олимпиадага баручы укучылар сайлап алына: ул телне, әдәбиятны белә, яратып өйрәнә, татар дөньясы белән кызыксына. Иң мөһиме: аның теләге бар! Шулай итеп әзерләнү нәтиҗәсен бирә. Быел республикабызда олимпиадалар IV сыйныфтан ук башланды. Бу бик яхшы дип уйлыйм мин. Бала кече сыйныфтан ук көрәшергә, авырлыкларны җиңәргә өйрәнә.

Балаларның олимпиадаларга әзерләнү вакыты - укучы, укытучы, ата-ана өчен җитди чор. Уңышлы чыгыш ясау өчен укучыга барлык көчен куярга кирәк. Олимпиадада җиңүләргә укучының интеллектуаль, физик һәм психологик әзерлеге сорала. Олимпиада имтихан бирүгә охшаш, бу бәйгедә дә укучы стресс кичерә. Укучыга таныш булмаган мохит, кешеләр дә, биремнәр үтәүгә бирелгән вакыт чикләнгәнлеге дә тәэсир итә. Укучы алдында барлыкка килгән киеренкелектән чыгуга педагог-психологның ярдәме бик зур була. Авыл мәктәпләрендә, кызганычка каршы, психолог штаты каралмаган. Шуңа күрә, олимпиадага әзерләүче укытучыга педагог-психолог ролен дә үтәргә туры килә. Укытучының бурычы- позитив эмоциональ халәт тудыруда ярдәм итү, курку-шикләнүләрне тарату, хис-кичерешләр, ихтыяр һәм психофизик торышны идарә итү алымнарына өйрәтү. Олимпиада чоры киеренкелеге "олимпиадада катнашучының" үзбәясе белән дә бәйле булырга мөмкин. "Мин бик акыллы, мин күп беләм, үземне тиешле дәрәҗәдә ачам, биремнәрне үти алам",- дип тә уйлый укучы. Барлык бу факторлар борчылу тудыралар, ә ул эшчәнлекне тарката, игътибар һәм эшкә омтылышны киметә. Хәтта сәләтле укучы да кирәкле дәрәҗәдә белемен, күнекмәләрен күрсәтә алмый.

Олимпиадада катнашучының акыл үсеше һәм белем – күнекмәләр формалаштыру өчен укытучы җавап бирә. Олимпиадага әзерләнүчегә ярдәм итә алырдай түбәндәге психологик алымнарны да күрсәтергә була:

- үзоештыруның югары дәрәҗәсе;
- югары һәм ныклы эшчәнлек;
- игътибарлылык, булдыклылык тупланмасының югары дәрәҗәдә булуы;
- төгәллелек, оешканлылык, стандарт булмаган фикер йөртүчәнлелек;
- эчке хәрәкәт планы формалашкан булу;
- стресска бирешмәүчәнлелек олимпиадада югары нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә.

Ә үзбәянең адекватсызлыгы, тырышуның күпертелгән яки түбәнәйтелгән дәрәҗәсе, баланың артык шомлануы олимпиада нәтиҗәсенә тискәре йогынты ясарга мөмкин.

Балага психологик ярдәм итүнең төрле ысуллары бар. Мин эш тәҗрибәмдә түбәндәге алым-ысулларны кулланам:

Олимпиадага әзерләнүче бала белән индивидуаль консультацияләр, стресска бирешмәүчәнлек дәрәҗәсен билгеләүне өйрәтә торган “Үзең белән идарә итә бел!” исеме астында дәресләр үткәрәм.

Укучыларга, акыл үсешенә тәэсир итә торган ярышларда катнашканда, күп информацияне хәтердә калдырырга туры килә, шуңа күрә хәтердә калдыру чараларына, материалны логик эшкәртү күнекмәләренә өйрәтәм.

Укучыларга олимпиада вакытында үзеңне ничек тоту турында киңәшләр бирәм. Психологик күнегүләр ярдәмендә нерв-психик киеренкелекне дә таратырга өйрәтәм.

Саналып киткән күнекмәләрне белү укучыларга, бигрәк тә, республика күләмендә олимпиада да катнашканда кирәк. Балаларга өйдән читтә үз көчләрен сынау вакытында иң якын кеше - озата баручы укытучы. Мондый укытучы ролендә мин үзем дә күп мәртәбә катнаштым. Анда инде син балаларның иң якын кешесенә әвереләсең: юатасың, көйлисең, олимпиадага теләкләреңне юллап озатасың. Ә аннары төн йокыларыңны калдырып, шул укучылар белән кайгырып, шатлык-сөенечләре белән уртаклашасың.

Димәк, олимпиадада катнашучы укучыны психологик әзерләү бик мөһим һәм зарури чара булып тора.

Югарыдыгы фикерләрдән соң мин шуларны әйтәсе килә. Әгәр укытучы үзе дә җитәрлек күләмдә гыйлемле, акыллы, яңалыклар белән алга омтылучы педагог та, психолог та икән, якын иптәш, сердәшче дә була белсә, аның шәкертләренә дә һәрвакыт уңыш елмаячак.

Минем укучыларым да татар теле һәм әдәбият фәннәре буенча үткәрелә торган олимпиадаларда катнашалар. Аларны күп еллар олимпиадаларның муниципаль турында да, республикакүләм турда да алдынгылар рәтендә күрергә мөмкин. Соңгы елларда үткәрелә башлаган халыкара олимпиада да үз көчләрен сыныйлар.

Олимпиадаларда катнашып, уңышларга ирешкән укучыларым югары уку йортларына кереп, киләчәктә телебезне саклаучы, яклаучы, үстерүче булырга әзерләнәләр.

## Ә.З. РӘХИМОВНЫҢ ИҖАДИ ҮСЕШ ТЕХНОЛОГИЯСЕ ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ АТЛЫЙ

***Шәйхетдинова Р.Ә.,*** *технолог-акмеолог,*
*31 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары Концепциясе белем-тәрбия процессын оештыруны да, эчтәлеген дә принципиаль үзгәртүне таләп итә. Яңа стандартлар буенча белем һәм тәрбия бирү системасының төп үсеш юнәлеше системалы - эшлекле юнәлеш дип билгеләнде. Үзләштерү процессының эшлекле характерда булуы турында тәгълимат Д.Б.Эльконин, В.В. Давыдовлар тарафыннан үткән гасырның 30 нчы елларында бәян ителде. П.Я. Гальперинның фикерләү гамәлләрен этаплап үстерү теориясенә таянып, иҗади үсеш технологиясен Ә.З. Рәхимов эшли.

Укыту ысулларының нәтиҗәлелеге турында кытайларның үтемле әйтеме бар: “Ишетәм - онытам; күрәм – аңлыйм; эшлим – истә калдырам”.Федераль дәүләт стандартларның иң мөһим таләбе – белемнәрне үзләштерү процессын укучыларның үз эшчәнлекләре нигезендә оештыру, ягъни «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш». Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Иҗади үсеш технологиясенең нигезендә эшлекле белем ята. Технология федераль дәүләт стандартларына җавап бирә һәм 3 парадигмага, ягъни 3 системага :

1) Д.Б. Эльконин - В.В. Давыдовның үстерешле укыту системасына;

2) Л.В. Занковның үстерешле укыту системасына;

3) Шәхескә юнәлгән укыту системасына нигезләнә.



Хезмәтебездә психология фәннәре докторы Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе тәгълим-тәрбия процессының көтелгән нәтиҗәлеген гарантияләүче факторларның берсе – укучыларның танып белү процессын нәтиҗәле оештырыга ярдәм итүче механизм – педагогик технология буларак тәкъдим ителә.

Иҗади үсеш технологиясе укытучыга дәрестә балаларның уку эшчәнлеген оештыру өчен зур мөмкинлекләр бирә. Уку эшчәнлегендә рефлексив фикер йөртү механизмның беренче адымы булып төшенчә кертелә. Төшенчә – белемнең бер формасы. Төшенчәне укучы эшчәнлегенә кертү өчен иң мөһиме – мәсьәләне (төшенчәне) өлешләргә бүлү, максатын, шарталарын билгеләү.

ИҮТ үзенең максатлары, эчтәлеге, уку-укыту методлары, формалары, уку-укыту процессында катнашучыларның үзара мөнәсәбәтләре буенча шактый үзенчәлекле. Укучы, уку эшчәнлегенә өйрәнер өчен укуның сыйфат ягыннан мөһим 3 этабын үтә.

Үстерешле уку-укытуның беренче этабында төп максат итеп уку эшчәнлегенең психологик механизмнарын булдыру куела. Психологик механизмнар укучыларга уку мәсьәләсен куярга, аны чишү юлларын һәм ысулларын табарга ярдәм итә. Психологик механизмнар булдыруның беренче адымы булып укучы эшчәнлегенә төшенчә кертү тора. Төшенчә – ул белемнең аерым бер формасы. Төшенчәдә өйрәнелә торган объект белән эш итүнең төп ысулын барлыкка китергән гамәлләр билгеләнелә.

Башлангыч сыйныф программалары төшенчәләр белән эш итүгә таянып төзелә. Югары сыйныфларда төшенчә үзенчәлекләре катлаулана.Төшенчәне укучы эшчәнлегенә кертү өчен берникадәр хәзерлек үткәрергә кирәк. Укучыда уку эшчәлегенең иң әһәмиятле механизмы булган максат кую, ягъни чираттагы уку мәсьәләсенең эчтәлеген билгеләү сәләте тәрбияләү кирәк. Иң мөһиме - мәсьәләне кисәкләргә бүлү, аның максатын, шартларын, чишү өчен эш итү чараларын билгеләү. Контроль һәм бәяләү гамәлләренең сыйфаты үзгәрә. Алар рефлексив характер алалар, яңа мәсьәләләр чишү юлын ачыклауга юнәлтеләләр һәм алга таба фикерләү ысулына көчә баралар. Алга таба укучылар аерым бер төшенчәгә караган теоретик уку мәсьәләсен генә чишеп калмыйлар, ә төшенчәләр системасы белән эш итәләр.Бу шартларда башта контроль һәм бәя бирү юнәлешендә барлыкка килгән рефлексия фикерләү характеристикасына әйләнә бара. Рефлексия фикерләүнең, зиһенгә алуның дәрәҗә күрсәткече булып тора. Шул рәвештә укучыда уку эшчәлеге формалаша.

Нәрсә соң ул - уку эшчәнлеге? Ул – яңа белемнәр туплауны максат итеп куйган эшчәнлек. Белем алу төп шөгыль булганда гына уку эшчәнлеге санала. Аның төзелеше моннан гыйбәрәт: 1) Белем алу бурычы кую – укучы нинди белемнәр алырга тиешлеген күзаллый. 2) Бу бурычны үтәү өчен эшеңне оештыру. 3) Алган белем күнекмәләренә үзбәя кую, бәяләү. Инновацион укыту системасында укытучы бәясе – тышкы бәя, укучы бәясе – эчке бәя (укучы үз эшчәнлеген бәяли), ә билге – укуга кызыксындыруны тәэмин итүче чара.Уку эшчәнлеге һәм бәяләү этаплап башкарыла.

Иҗади үстереп укытуга корылган технология телнең фәнни нигезләрен өйрәтүдә башка төрле юллар барлыгын исбатлады. Белем бирү эчтәлеген яңарту, укыту һәм тәрбияләү методларын камилләштерү максатында иҗади үсеш технологиясен практикага кертү укытучыларга ярдәм итәргә тиеш. Иҗади үсеш технологиясе буенча дәресләрдә укучылар мавыгып, уку мәсьәләсен куеп, аны чишү юлларын кызыксынып эшлиләр. Каршылыклар укучыларны уйландыра, мәсьәләне мөстәкыйль чишәргә мәҗбүр итә. Мөстәкыйль табылган нәтиҗә яхшырак үзләштерелә, белемнең сыйфаты да югары була һәм озак вакыт хәтердә саклана. “Белем – мәктәптә укытканның барысын да онытканнан соң калганы ул”, - дип, А.Эйнштейн юкка гына әйтмәгәндер. Биргән белемнәребез төпле,төшле булса иде!

Иҗади үсеш технологиясе Түбән Кама шәһәренең 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбендә 2010 елдан өйрәнелә.Технология серләрен Түбән Кама педагогия көллиятенең татар теле һәм укыту методикасы буенча технолог-акмеолог Р.Ә. Шәйхетдинова ачты.

Эшнең беренче нәтиҗәләре белән таныштыру максатыннан, 2012 нче елда психология, педагогика фәннәре докторы, профессор Ә.З. Рәхимов һәм Россия Федерациясе мәктәпләренең атказанган укытучысы В.С. Казыйхановларны чакырып, татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен регионара семинар-практикум үткәрелде. Әлеге дәресләрнең нәтиҗәлелеген күреп, мәгариф идарәсе методистлары тәкъдиме белән, 2016-2017 нче уку елында Түбән Кама муниципаль районы укытучылары өчен шәһәрнең 31 нче мәктәп нигезендә педагогик остаханә оештырылды. Остаханә эше Рәфидә Әслах кызы Шәйхетдинованың “Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе буенча белем һәм тәрбия бирүнең теория һәм практикасы” авторлык программасына нигезләнде. Остаханә дәвамында, теоретик белемнәрне практика белән ныгыту өчен, башка татар теле һәм әдәбияты укытучыларының да видео дәресләре карап анализланды. Әлеге остаханәдә шәһәр һәм район мәктәпләреннән 45 укытучы үз һөнәри осталыкларын күтәрде. Остаханәнең эшен йомгаклап, 2017 нче елның 14 нче мартында Республика күләмендә «Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе - һәр укучының үсешенә һәм сәләтен ачуга шартлар тудыручы төп фактор» дигән темага республика семинары үткәрелде. Аңа кунак булып Ә.З. Рәхимов технологиясе буенча дәреслек авторы, Яр Чаллы шәһәрендәге 30нчы мәктәпнең югары кв.категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәсәншина Резедә Гатаулла кызы һәм ЧДПУның татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту методикасы кафедра доценты, филология фәннәре кандидаты Мөхиярова Рәзинә Хәйбрахман кызы да чакырылды. Семинар барышында 2мастер-класс һәм 6 ачык дәрес күрсәтелде. Соңыннан Шәйхетдинова Р.Ә. һәм Бәдгыева Э.Д. чыгышлары тыңланды. Катнашучылар семинарга югары бәя бирделәр. Остаханәнең эшенең беренче нәтиҗәсе буларак “Эзләнүләр һәм табышлар” методик ярдәмлеге басмага әзерләнә.

## ОСТАХАНӘЛӘР ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Зарипова Әнисә Газизулла кызы,***
*Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиянең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



*Зарипова Ә.Г.*

2016-2017 нче уку елында шәһәр мәгариф идарәсе боерыгы нигезендә укучыларны Бердәм республика тестын уңышлы тапшыруларына әзерләү буенча педагогок остаханә төзелде. “Татар телендә белем бирү мәктәпләрендә белем алучы укучыларны Бердәм республика тестына әзерләү” остаханәсенең җитәкчесе итеп Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зарипова Әнисә Газизулловна билгеләнде.

Педагогоик остаханә план нигезендә түбәндәге максат һәм бурычларны күздә тотып эшләде:

- татар теле укытуның сыйфатын арттырып, укучыларның Бердәм

республика тестын уңышлы тапшыруларына җирлек тудыру;

- контроль-бәяләү материалларының төзелешен һәм эчтәлеген өйрәнү;
- укучыларда тест биремнәрен гамәли эшли алу күнекмәсен булдыру;
- укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, иҗади биремне үтәү барышында әдәби һәм халык авыз иҗаты әсәрләреннән мисаллар китерә алуларына ирешү.

Әнисә Газизулловна беренче җыелышта педагогик остаханәнең эш планы, максаты, бурычлары, БРТ тапшыру буенча норматив, контроль-бәяләү документлары, бланк тутыру, кулланма әдәбият белән таныштырды.

Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучылары Хаҗиева Зилия Галиевна "Тест өлешен башкару", Шәймөхәммәтова Фәнзилә Мирзануровна "Кыска изложение язу", Зарипова Әнисә Газизулловна "11.1, 11.2 биреме буенча сочинение язу" исемле темаларга мастер-класслар күрсәттеләр.

Муса Җәлил исемендәге 1 нче гимназия укытучылары: Хәйруллина Гөлназ Рәшитовна "Стилистик синонимнар", Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәммәтовна "Иярченле кушма җөмлә" темаларына ачык дәресләр күрсәттеләр.

Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы Гарипова Лилия Рәүфовна "Укучыларны БРТга әзерләүдә кыенлыклар" темасына чыгыш ясады.

Укытучыларга укучыларны Бердәм республика тестына әзерләүгә ярдәм йөзеннән уздырылган мастер-класслар, дәресләр, чыгышлар югары дәрәҗәдә үтте, соңыннан түгәрәк өстәл янында эшлекле сөйләшүләр алып барылды.

15 нче февраль көнне Шәһәр мәгариф идарәсе тарафыннан БРТын сынап карау үткәрелде. Сынау эшләрен барлыгы 213 укучы башкарды. Каенлы гомуми урта мәктәбе, Кызыл Чапчак төп гомуми белем бирү мәктәбе, Югары Чаллы урта гомуми белем бирү мәктәбе укучыларының күрсәткечләре бик яхшы. Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназия, Муса Җәлил исемендәге 1нче гимназия, Шәңгәлче гомуми урта белем бирү мәктәбе, Түбән Уратма урта гомуми белем бирү мәктәбе, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 10 нчы гомуми урта белем бирү мәктәбе укучыларының белем сыйфаты нәтиҗәләре уртача, 15 нче гомуми белем бирү мәктәбе, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе укучыларының белем сыйфатын, өлгереш күрсәткечләрен үстерү буенча нәтиҗәле эшчәнлек алып барырга кирәк.

Остаханә җитәкчесе Әнисә Газизулловна тарафыннан сынау нәтиҗәләренә анализ ясалды. Түбән Кама муниципаль районы Милли мәгариф урынбасарлары семинарында аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 10 нчы гомуми урта белем бирү мәктәбе укытучысы Гәрәева Гөлнара Рыяновна сынау нәтиҗәләре турында чыгыш ясады.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: укучыларның Бердәм республика тестын уңышлы тапшыруларына әзерләү юнәлешендә күләмле эшчәнлек алып барылды, нәтиҗәсе уңышлы булыр дип ышанасы килә.

## БЕРГӘЛӘП ЭШЛӘСӘК...

***Габдуллина Кадрия Тимерҗановна,***
*27 нче урта белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*татар төркемнәрендә эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларының*
*шәһәр методик берләшмәсе җитәкчесе*


*Габдуллина К.Т.*

2016-2017 нче уку елында Бердәм Республика тестларына әзерләнү буенча педагогик остаханәләр Шәһәр Мәгариф идарәсе боерыгы нигезендә өч юнәлештә: татар мәктәпләрендә эшләүче, рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына белем бирүче һәм татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче укучыларны өйрәтүче укытучылар өчен эшләде. Үткән уку елында аерым бер мәктәптә укытучыларга ачык дәрес оештыруда методик ярдәм күрсәтеп, эш төрләрен бергә карасак, быел теоретик якка да

чагыштырмача күп игътибар бүленде, консультацияләр оештырылды, мастер-класслар да күрсәтелде. Җыеп әйткәндә, 2015-2016 нчы уку елында оештырып җибәрелгән бу башлангыч татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен файдалы булуына тагын бер тапкыр инандык.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балалары белән эшләүче укытучылар өчен остаханә 27 нче мәктәп базасында оештырылды. Шәһәр һәм район мәктәпләренең татар төркемнәрендә эшләүче 29 укытучысы бу остаханәгә чакырылды. Иң элек укытучылар белән остаханә эшчәнлеге буенча план төзелде, максат һәм бурычлар куелды, доклад һәм консультацияләрнең темалары, мастер-класс һәм ачык дәрес күрсәтәчәк укытучылар билгеләнде. Һәр айда утырышлар оештыру, анда көн тәртибендә каралачак сораулар билгеләнде. Аннары утырышларны үткәрү көннәре ачыкланды.

Уку елы дәвамында остаханәнең биш утырышы үткәрелде:

- беренче утырышта БРТ үткәрү буенча Фән һәм Мәгариф министрлыгы тарафыннан җибәрелгән норматив документлар белән таныштык (искә төшердек), 22 нче код буенча бланкларны өйрәнү һәм дөрес итеп тутыру каралды. Яшь укытучылар һәм беренче тапкыр БРТна әзерләүчеләр өчен бу эш – иң әһәмиятлеләрдән берсе. Укытучылар алдында 30 ел эш стажы булган тәҗрибәле укытучы Гыйләҗетдинова З.З. (27 нче мәктәп) чыгыш ясады һәм тыңлаучыларның күп санлы сорауларына җавап бирде;
- ноябрь аенда үткәрелгән икенче утырышта татар теле һәм әдәбияты укытучылары Фәттахова И.И. (13нче гимназия-интернат) һәм Шәйхиева Н.С. (5нче мәктәп) мастер-класс күрсәттеләр. Шулай ук Казанда укучыларны БРТна әзерләү өчен «Укучыларны татар теленнән БРТ, ОГЭ, БРИ сынауларын уңышлы тапшыруга әзерләү технологиясе» дигән темага үткәрелгән семинар материаллары белән Габдуллина К.Т. (27нче мәктәп) таныштырды;
- өченче утырыш 35нче лицейда оештырылды. 2015-2016 нчы уку елында югары күрсәткеч биргән укытучылар Ибраһимова Н.М., Яруллина Г.С. ачык дәрес әзерләп күрсәттеләр. Лицей укытучылары Хужанбердиева Ч.Т. һәм Галиева Г.Г. чыгышлары тыңланды. Планда каралганча, укытучылар ачык дәресләрендә 20 нче тест биремен эшләү, материалны авыр үзләштерүче укучылар белән индивидуаль эш төрләрен башкару буенча тәҗрибә уртаклаштылар;
- алдагы утырышта түгәрәк өстәл артында эшлекле сөйләшү оештырылды, Фән һәм Мәгариф министрлыгы сайтында урнаштырылган демоверсияләр өйрәнелде;
- 15 нче февральдә Бердәм Республика тестларын сынап карау уздырылды. Татар төркемнәре 31 мәктәптә бар, анда барлыгы 445 укучы исәпләнә. Тестларны 420 укучы язды, төрле җитди сәбәпләр аркасында 11е, кызганычка каршы, яза алмады (авыру, ярышларда булу, республика олимпиадасында катнашу һ.б.) Нәтиҗәләр: “5”ле – 60 укучы; “4”ле – 141 укучы, “3”ле – 161 укучы алды. 58 укучыга, җитәрлек балл җыя һәм сочинение яза алмаганга, “2” ле куелды. Шулай итеп, өлгереш – 86%, ә сыйфат 47,7%; уртача билге – 3,39 булды;
- дүртенче тапкыр укытучылар БРТын сынап караганнан соң, 15 нче мартта очрашты. Анда Татар төркемнәрендә Бердәм республика тестларын сынап карау нәтиҗәләре буенча мониторинг ясалды, хаталар өстендә эш үткәрелде.

Тест өлешендәге 20 биремне укучылар, нигездә, эшләгәннәр. Теориядән белем базасы бар, укытучылар да яхшы аңлатканнар һәм әзерләгәннәр, 20шәр балл алучылар да шактый булды. Типик хаталарга җөмләдән билгеле бер килештәге сүзне ияртүче сүзе белән (сүзтезмәне) аерып алу, метафоралы җөмләне табу, тыныш билгеләрнең дөрес куелышын кертергә мөмкин.

Татар төркемнәрендә укучы балаларның иҗади эшләрен тикшергәннән соң, шундый нәтиҗәләр ясалды:

- татар төркемендә укучы балаларның сөйләм теле бик ярлы, сүзлек запасы аз, фикерләрен матур итеп җиткерә алуда кыенлыклар бар;

- 21.2. биремнәрен сайлаучылар аз, якынча 5 % укучы гына сайлап алган; бу – укучыларның туган телне җитәрлек дәрәҗәдә аңламавы нәтиҗәсе һәм бирелгән тексттан читкә китәргә куркулары;
- кайбер укучылар язмаларында рус сүзләре дә кулланганнар, димәк, сүз байлыгы юк;
- бер җөмләдә кабатланган сүзләр очрады; синонимнарны куллана белмибез;
- кереш сүзләрне кирәгеннән артык язган, тыныш билгеләре үз урынында булмаган эшләр дә шактый;
- дәлилләрне тексттан күчереп кенә куючылар да бар.

Әйтеп үтелгән хаталарны игътибардан читтә калдырырга тиеш түгелбез. Эшлисе эшләребез бик күп. Хаталар өстендә эшләп, җитешсезлекләрне төзәтеп, тагын да нәтиҗәлерәк күрсәткечләргә ирешсәк иде...

Безнең максатыбыз – Бердәм Республика тестларын мөмкин булган кадәр яхшырак итеп тапшыру. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен дә бу зур сынауны үтү өчен бар белемне, көчне һәм вакытны кызганмаска кирәк. Укучыларны кызыксындырыр өчен яңа эш төрләре, алымнар да тапсак иде. Һәр укытучы укучылар, сыйныф җитәкчеләре һәм ата-аналары белән берлектә эшләсә, нәтиҗәләребез яхшырыр дип өметләник!

## *ТАТАР ТЕЛЕННӘН БРТ (БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ТЕСТЫ): ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАР...*

***Гыйләҗетдинова Зәнфилә Заһит кызы,***
*27 нче мәктәпнең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

*Соңгы елларда, уку-укыту системасына яңалыклар кертелү сәбәпле, укучылар һәм укытучы алдына куелган таләпләр үзгәрде, башка бурычлар куела башлады. Алар уку-укыту әсбаплары алышынуында, дәрестә яңа эш төрләрен һәм алымнарын куллануда, информацион технологияләрне файдалануны активлаштыруда, белемне тикшерү системасы үзгәрүдә һ. б. да чагылыш табалар. Мондый үзгәрешләр, башка барлык фәннәргә караган кебек үк, тел дәресләрен дә читләтеп үтми.*



*Гыйләҗетдинова З.З.*

IX сыйныфны тәмамлаганда, татар теленнән имтихан тапшыру мәҗбүри иде. Сынаулар традицион формада гына узды. Туган (татар) телендә белем алган укучылар - сочинение элементлары белән изложение, рус телендә белем алган татар телле укучылар диктант яки изложение яза алды. Ә рус телле укучылар билетлар буенча сынау тотты. Моңа кадәр укучылардан укылган яки тыңланган текстка мөмкин кадәр якын булган эчтәлектәге тулы изложение язу сорала яки билгеле бер темага ирекле сочинение яисә нинди дә булса укылган әсәргә карата, үз фикереңне белдереп, сочинение язу таләп ителә иде. Ә БРТ (бердәм республика тесты) да күләме ягыннан чикләнгән, укылган текстта әйтелгән фикерне дәлилләп язылган сочинение язу таләп ителә.

2014 елдан Татарстан республикасының барлык мәктәпләрендә дә 9нчы сыйныф укучылары татар теленнән имтиханны яңача, тест рәвешендә тапшырдылар. Татар теленнән башкарылган тест эшләре укучыларның лингвистик белемнәрне күрсәтү, шулай ук танып белү, төркемләү һәм фикер йөртүгә кагылышлы белем һәм күнекмәләрне чагылдыра. Тестта бирелгән контроль бәяләү материаллары укучыларның лексик, грамматик, стилистик, орфографик кагыйдәләрне һәм пунктуация нормаларын белү һәм ачыклауга юнәлдерелгән.

Биремнәрнең эчтәлеге, шулай ук аларны башкару вакыты укучының татар телен ни рәвешле – ана теле яки дәүләт теле буларак өйрәнүенә карап билгеләнә.

Татар теленнән БРТ, Татарстан Республикасында гамәлдә булган уку-укыту программаларына нигезләнеп, 3 төркем өчен махсус әзерләнгән контроль бәяләү материаллары буенча үткәрелә: беренче төркем - татар телендә гомуми белем бирүче

оешмаларның IX сыйныф укучылары өчен, икенче төркем - рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен, өченче төркем - рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның рус төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен әзерләнгән материалларга нигезләнә. Ана телен татар мәктәбендә һәм рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендә укучыларга 240 минут, ә рус төркемнәренә 150 минут вакыт бирелә.

Тестлар Бердәм дәүләт имтиханын тапшыру өчен төзелгән контроль-исәпләү материалларына (КИМ) охшаш. Имтихан эшендә сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр, кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр һәм укучының тәкъдим ителгән темага үз фикерен белдерә алуын тикшерүгә юнәлдерелгән ачык типтагы биремнәр файдаланыла.

Рус мәктәбендә белем алучы татар балалары 20 тест бирем эшлиләр һәм, текстка нигезләнеп, сочинение язалар. Имтихан эшенең 1 нче өлешен компьютер, ә сочинениене, билгеле бер критерийларга нигезләнеп, экспертлар тикшерә.

Ә хәзер сочинение язуга тулырак тукталып китик. Сочинение фикерләмә-билгеле бер фикерне дәлилләп язылган текст. Анда язылган фикерләр укылган тексттан алынган мисаллар (2 мисал) белән дәлилләнеп барырга тиеш. Сочинениедә 3 абзацның булуы мөһим.

Биремне үтәгәндә, төп 3 элементның булуы таләп ителә:

- тезис,
- дәлилләр (укылган тексттан мисаллар),
- нәтиҗә .

Сочинение язганда, укучы еш кына түбәндәге хаталарны ясый:

- сорауга җавап кына язу;
- текстның исемен дәлил итеп китерү;
- дәлил китергәндә, җөмләнең санын гына язу(12, 15 җөмлә -12 нче җөмләдә...яки 12-13 нче җөмләләрдә.. дип язарга кирәк)-грамматик хата;
- тексттан ике дәлилнең булмавы;
- текстны күчереп язу;
- кызыл юлларга бүленеш дөрес түгел һәм алар арасында бәйләнешнең булмавы;
- текст төзеклегендә хаталар: башлам яки йомгак өлеше булмау;
- диалектлар белән язу(апкилә, апае)-сөйләм хатасы;
- эшнең төгәлләнмәгән булуы (нәтиҗә булмау);

Укучылар эшендә хаталарны киметү өчен түбәндәге үрнәктән;

файдалану отышлы дип уйлыйм.

Текст “.........................” сүзләре белән тәмамлана. Минемчә, автор (исеме, фамилиясе) бу өзектә ... турында сөйли. ( 21.2 нче биремгә игътибар итәргә чакырам)

Нәрсә соң ул ....? Мин аны ничек аңлыйм? (3-4 җөмлә белән үз фикерләрен язарга өйрәтәм). Дәлил: (Ни өчен?) Бу чыннан да шулай, *чөнки*........ Автор әлеге фикерне 15-16 нчы җөмләләрдә ачык чагылдырган.

Шулай итеп, язучы безгә .... турында аңлата. Ул безне .... булырга чакыра, .... булырга өнди.

Сочинениене бәяләгәндә, текстның мәгънәсен аңлауга, тексттан табылган мисалларның булуына, сочинениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелегенә, эшнең композицон төзеклегенә игътибар ителә. Күрсәткечләр буенча сочинение өчен иң югары 9 балл куела. Ләкин шунысына да игътибар итәргә кирәк: әгәр сочинение тулысынча күчереп язылган текстка туры килә икән, аңа бөтен критерийлар ($C_2$К1-$C_2$К4; ГК1-ГК4, ФК1) буенча да 0 балл куела.

Укучының грамоталылыгы һәм язма сөйләмнең төгәллеге изложение һәм сочинение тикшерү нәтиҗәсендә тупас һәм тупас булмаган яки төрле һәм бер үк типтагы хаталарны исәпкә алып бәяләнә.

Грамоталылыкны бәяләгәндә, (ГК1-ГК4) сочинениенең күләме исәпкә алына. Сочинениенең күләме 100 сүздән ким булмавы шарт.

Чыгышымны йомгаклап шуны әйтәсем килә: укучы лексик, грамматик, стилистик, орфографик кагыйдәләрне һәм пунктуация нормаларын яхшы үзләштерсә, фикерли алса,

имтиханны яхшы гына билгеләргә тапшыра ала дип уйлыйм. Дөрес, укучы татар теленнән генә имтихан тапшырмый. Монда инде безнең дә ярдәм кирәк.

## БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ТЕСТЫНА БЕРГӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ

***Насыйбуллина Д.Ф.,*** *8 нче урта белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы, рус төркемнәрендә эшләүче*
*татар теле һәм әдәбияты укытучыларының муниципаль методик берләшмәсе җитәкчесе*


*Насыйбуллина Д.Ф.*

2016-2017 нче уку елында мәгариф бүлегенең боерыгы белән татар теле һәм әдәбияты укытучыларының 3 педагогик остаханәсе эшләде. Бу – рус төркемнәрендә, татар төркемнәрендә, татар сыйныфларында чыгарылыш сыйныф укучылары белән эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларының остаханәләре. Рус төркемнәренең чыгарылыш сыйныфлары укучылары белән эшләүче укытучылар төркеме шәһәр һәм район мәктәпләрендә эшләүче 70 тән артык укытучыны берләштерде. Педагогик остаханәнең төп темасы: “Рус төркемнәрендә чыгарылыш сыйныф укучыларын БРТ енә әзерләү”, максаты - татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән төп гомуми белем бирү мәктәбендәге рус телле укучыларның татар телендә коммуникатив компетенциягә ия булулары өстендә эшне нәтиҗәле итеп оештыру иде. Остаханә түбәндәге бурычларны хәл итү өстендә эш алып барды:

- Рус телле укучылар белән Бердәм республика тестына әзерлекне түбәндәге лексик һәм коммуникатив бурычларны хәл итәрлек итеп оештыру:
- Татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик яктан дөрес төзергә күнектерү.
- Исемнәрне килешләрдә төрләндерә белү, сөйләмдә дөрес кулланугa ирешү.
- Тартымлы исемнәрне килешләрдә төрләндерү, текстта таный белү.
- Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру.
- Рус телен татар теле белән чагыштырып, аермаларны күрә һәм дөрес куллана белү.
- Рус теле һәм татар телендә җөмлә төзелешендә аерманы аңлый белү.
- Сорау җөмләләрне дөрес төзергә өйрәнү, язма сөйләмнең дөреслегенә ирешү.
- БРТ биремнәрен аңлап, дөрес башкаруга ирешү.
- Шәхси хат язарга өйрәнү.

28 нче октябрь көнне 8 нче гомуми урта белем бирү мәктәбендә рус телле төркемнәрдә эшләүче укытучыларның педагогик остаханәсе үзенең беренче утырышын үткәрде. Остаханә утырышына шәһәр һәм район мәктәпләрендә 9 нчы сыйныфның рус төркемнәрендә эшләүче 70 тән артык укытучы килгән иде. Утырышта укучыларны тестированиегә әзерләү буенча эшлекле сөйләшү уздырылды. Рус телле укучылар белән эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары остаханәнең максаты, бурычлары, эш планы белән таныштылар. Сөйләшү барышында БРТ биремнәренә күзәтү ясалды, быелгы уку елында кертелә башлаячак телдән сөйләмне тикшерү күнегүләренә аерым басым ясалды. 8 нче мәктәпнең татар теле укытучысы Ногманова Г.Ф. БРТ бланклары, аларны дөрес тутыру кагыйдәләре турында чыгыш ясады. Шул ук мәктәп укытучысы Галина В.М. БРТ биремнәренең берсе булган шәхси хат язу серләренә өйрәтте. Утырышка килгән укытучылар үзләрен борчыган мәсьәләрне уртага салып сөйләштеләр. Утырыш эшен йомгаклап, мәгариф бүлегенең укыту-методик бүлеге методисты Сабирова Г.Х. чыгыш ясады, укытучыларның сорауларына җавап бирде.

25 нче ноябрь көнне 8 нче гомуми урта белем бирү мәктәбендә рус телле төркемнәрдә эшләүче укытучыларның педагогик остаханәсе үзенең икенче утырышын үткәрде. Утырышка килгән укытучыларны мәктәп директоры Сергеев Анатолий Степан улы сәламләде, кыскача мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик

берләшмәсе эшчәнлеге белән таныштырды, килгән кунакларны Халыкара әниләр көне белән тәбрикләде. Бу котлауларга мәктәпнең милли эшләр буенча директор урынбасары Нуриева Рәмзия Фәрваз кызы да кушылды.

Утырышта укучыларны тестированиегә әзерләү буенча эшлекле сөйләшүне дәвам иттеләр. Рус телле укучылар белән эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларның шәһәр методик берләшмәсе җитәкчесе Насыйбуллина Д.Ф. Шушы көннәрдә генә Казан инновацион университеты татар теле укытучылары өчен оештырган семинарда булып кайткан иде. Ул остаханә утырышына килгән укытучылар белән шул семинардан алган тәэсирләре белән уртаклашты, тестирование үтүгә кагылышлы яңалыклар, үзгәрешләр турында сөйләде. Укытучылар чыгышны бик кызыксынып тыңладылар, быелгы уку елында кертелә башларга мөмкин булган телдән сөйләмне тикшерү күнегүләре буенча күп сораулар бирделәр. 8 нче мәктәпнең татар теле укытучысы Ногманова Г.Ф. БРТ дагы 3 нче бүлек материаллары – грамматик һәм лексик күнекмәләрне тикшерә торган биремнәр буенча эш тәҗрибәсе белән уртаклашты, шул мәсьәләне яктырткан презентациясе укытучылар арасында таратылды.25 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучылары 18-32 нче биремнәр өстендә эшләү алымнары турында сөйләде. 25 нче гимназиядән Гайнетдинова И.И. "Рус телле укучыларны бердәм республика тестына әзерләү һәм хаталарны булдырмау юнәлешендә эш алымнары, 18-32 биремнәр" дип аталган чыгышы да шул ук мәсьәләне яктыртты. Һәр укытучының башкалар белән уртаклашырлык үз эш алымнары, үз уңышлары бар, шуңа күрә аларның укучылары да тестирование күнегүләрен "2" лесез эшли алалар. Утырышка килгән укытучылар үзләре өчен бик күп файдалы мәгълүмат алулары турында ассызыкладылар, үзләрен борчыган сорауларга бергәләп җавап эзләделәр.

Остаханәнең өченче утырышы 32 нче гимназиядә үткәрелде. Рус төркемнәрендә эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары Ачаева Ч.Н., Билалова А.Р., Хафизова И.М. остаханә әгъзалары өчен чыгарылыш сыйныфларда ачык дәресләр күрсәттеләр. Дәресләрдә БРТ биремнәре өстендә практик эш оештыру алымнары ачык чагылыш тапты, өч укытучының да дәресенә югары бәя бирелде. Остаханә эшендә катнашучы башка укытучылар да үз эш алымнары турында фикер алыштылар.

15 нче февральдә районыбызның 9 нчы сыйныф укучылары татар теленнән бердәм республика тестированиесе форматында сынап карау эше башкардылар. Район мәгариф идарәсе белгечләре ярдәме белән оештырылган бу чарада шәһәр һәм район мәктәпләреннән 1814 укучы катнашты."5" гә – 91 укучы укучы язган, "4" гә – 528 укучы, "3" гә – 805, "2" гә – 210 укучы. Эшнең өлгереш нәтиҗәсе – 84 %, сыйфаты – 34% тәшкил итә. Трудовой, Кармалы, 32нче гимназия, 14 нче, 35 нче лицейның эш башкару сыйфаты 50% тан югарырак. 3 нче, 11 нче, 29 нчы, 31 нче һәм Елантау мәктәпләрендә дә "2" ләр саны шактый күп булды.

Остаханәнең чираттагы утырышында үткәрелгән сынап карау эшләренә нәтиҗә ясалды. Эшләрнең нинди дәрәҗәдә башкарылуына, нәрсәгә, кайсы биремнәргә күбрәк игътибар итәргә кирәклегенә тулы анализ ясалды. Бланк тутыру, тест биремнәрен эшләүдә укучылар җибәргән хаталар ассызыклап күрсәтелде.

Остаханә эшендә катнашучы укытучылар фикеренчә, шулай бергәләп эшләү, тәҗрибә уртаклашу, бер-береңнең эш алымнары белән танышу - чыгарылыш сыйныф укучыларын тестированиегә әзерләүдә бик файдалы ысул.

# ФЕДЕРАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ ШАРТЛАРЫНДА КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУДА Р.Р.НИГЪМӘТУЛЛИНА АВТОРЛЫГЫНДАГЫ «ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ» УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКСЫНЫҢ РОЛЕ

***Хәсәншина З.З.**, «21 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль гомуми белем бирү бюджет учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, милли мәгариф өчен җаваплы директор урынбасары*



*Хәсәншина З.З.*

Белем бирүнең төп һәм әһәмиятле максаты – яшь кешенең үзе куйган сорауларына җавап табарлык һәм куелган мәсьәләләрне чишәрлек, дөрес фикерли алырлык белемле булуына ирешү. Моның өчен балага белем бирүдә “инструмент”ларның ныклыгы, дөреслеге, уңайлы булуы таләп ителә. Укытудагы яңачалык әнә шул “инструмент” сыйфатында чагылыш таба. Нинди генә сәләтле, тәҗрибәле, белемле укытучы булмасын, балага белем бирүдәге “инструмент”тан дөрес файдаланмый икән, аның сыйфатына да зыян килә.

Заманча белем бирүдәге тагын бер мөһим як – баланы фикерләргә өйрәтү. Фикерли алган бала гына мең төрле сорауга җавап эзли, хаталана-хаталана булса да, эзләгәнен таба; эшендә, тормышында үзе эзләп алган белемне куллана. Шуңа күрә бүгенге укытучы алдында торган төп бурыч – балага белем нигезләрен бирү. Нәкъ ныклы, системалы белем нигезләре генә баланың белемне куллана алуына ирешүдә алшарт булып тора. Моңарчы белемне укытучы эзләп, табып, үтемле юллар аша балага бирсә, бүген инде укытучы белем алу юлларын күрсәтә, тәкъдим итә, фаразлый. Барлык баланың фикерен тыңлый, укучыга үзе сайлаганны дәлилләргә, исбатларга мөмкинлек бирә.

Югарыда искә алынган шартлар федераль дәүләт белем бирү стандартларының төп үзенчәлеге булып тора. Белем бирү белән беррәттән, балаларның танып белү активлыгын үстерү, уку эшчәнлеге күнекмәләрен формалаштыруга, максат куя һәм аны гамәлгә ашыру юлларын эзли белү, уку нәтиҗәләрен бәяләү күнекмәләрен үстерү – ФДББСның төп максаты. 2009 нчы елда стандартларга күчү турында боерык чыкты, ә 2015-2016 нчы уку елыннан 5 нче сыйныфларда яңа стандартларга нигезләнеп укыту башланды.

“Татарча да яхшы бел” УМК апробацияләүдә катнашкан укытучы-экспериментатор буларак та, рус телле балалрга татар теле өйрәтүдә стандарт таләпләренең аңлаешсыз урыннары күп булуыннан күңеле борчылган татар теле укытучысы һәм милли мәгариф өчен җаваплы урынбасар буларак та, тәҗрибәм белән уртаклашасым, таләпләргә карата фикеремне белдерәсем килә.

Системалы эшчәнлекле юнәлешнең төп максаты – шәхес үсеше. Шуңа күрә татар теле һәм әдәбияты дәресләренең дә структурасы шушы максатка карап төзелергә тиеш. Традицион дәресләрдән аермалы буларак, без 4 төрле дәрес тибының максатларын (яңа белемнәр ачу, рефлексия, белемнәрне системалаштыру, үстерешле контроль дәресләре) дөрес билгеләргә, укытучы һәм укучы эшчәнлеген оештырырга, һәм иң мөһиме – дәрес структурасы буенча белемнәребезне тирәнәйтергә тиешбез.

Рус телле укучыларның аралашу осталыгын булдыру – башлангыч сыйныфлардан ук укучылар белән эшләгәндә телгә өйрәтүнең төп максаты. Дәрес планнарында без аны коммуникатив максат итеп билгелибез һәм шуңа ирешү юллары алгоритмын башкарабыз. Без моны фәндә коммуникатив компетенция дип атыйбыз. Коммуникатив компетенцияне тәшкил итүче башка компетенцияләргә аерым тукталмыйм (компетенцияләр слайтта күрсәтелә), ләкин бу компетенцияләрне формалаштыруда дәреслекләр нинди роль уйный соң? Чөнки дәреслек – укыту эшчәнлеген оештыруда әйдәп баручы чара. Рузалия Рәхмәтулловна Нигъмәтуллина авторлыгындагы “Татарча да яхшы бел” УМК-сы бу өлкәдә уңышлы дәреслек дип саныйм. Үзем 5 ел республика эксперименты кысаларында катнашкан укытучы-эксперементатор буларак, 4 ел альтернатив дәреслек буенча эшләү дәверендә бу

дәреслекнең федераль дәүләт белем бирү стандартларына тулысынча җавап бирүенә инандым.

ФДББС-на “дәреслек системасы” төшенчәсе кертелде. “Дәреслек системасы” укучылар өчен китап белән беррәттән эш дәфтәре, мультимедиа, диск белән дә тәэмин ителешен күз алдында тота. Нигъмәтуллина Р.Р. тарафыннан төзелгән УМК ФДББСна күчкәнче үк гамәлгә кертелде. Аның өстенлеге шунда: коммуникатив компетенция формалаштыру юллары барысы да шушы УМК-га салынган. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча эш бер-берсенә бәйле рәвештә, параллель бара, ягъни һәр дәрестә диярлек сөйләм эшчәнлегенең 4 төре дә катнаша: ишетеп аңлау, уку, диалог, монолог. Бу эш төрләренә өйрәтүне системалы оештырганда гына, куелган максатка ирешеп була. 1 дәрескә алынган сөйләм дозасы шушы төрләр аша үтәргә. Дәрес вакытының 60-70% сөйләшүгә алына. Ә сөйләшүнең төп берәмлеге – сүз. Сүзне төрле калыпларда күреп, танып, ишетеп куллану – лингвистик компетенциягә керә. Шуңа күрә дә башлангыч этапта сүзләрне белүне бик нык таләп итәргә кирәк; аларны иң гади сөйләм үрнәкләре аша дөрес кулланырга, спонтан куллануга чыгу – бик җаваплы хезмәт. Ә 5 нче сыйныфтан башлап бу күнекмәләр, башка темалар аша тулыландырылып, аралашу ситуациясенең урыны, вакыты, катнашучыларның яшенә, җенесенә, социаль хәленә карап киңәйтелә. Без моны – социолингвистик компетенция дибез.

Предметларны сурәтләү, рәсемнәр, картиналар буенча сөйли белү, әлеге вакыйгага карата үз фикереңне әйтү яки бәя бирә белү – монологик сөйләмнең иң камил варианты. Бу эшнең башлангычы булып, дәреслектәге әйдәп баручы рәсемнәрнең ролен карап китик. Вакыйга кайда бара? Вакыйга кайчан бара? Рәсемдә кемнәр бар? Алар нишлиләр? Нәрсәләр бар? Синеңчә, бу нинди бәйрәм? Ни өчен шулай уйлыйсың? кебек сорауларны башта укытучы-укучы парында башларга кирәк. Һәрдаим башкарыла башлагач, рәсем буенча фаразлау (Бәлки, ... -дыр-дер-тыр-тер) кереш сүзләрне куллану (минемчә, әлбәттә, беренчедән, минемчә) белән баетыла бара. Соңрак, 7 нче сыйныфлардан башлап, сорауларны куймыйча гына, рәсем буенча сөйләшүгә чыгарга мөмкин. Мәсәлән, укучы: “Минемчә, вакыйга өйдә бара, чөнки әни, малай диванда утыра. Вакыйга, бәлки, ял көне, кич барадыр. Әнисе малайга китап бирә. Малайның укыйсы килми, аның футбол уйныйсы килә” – дип, сөйләү көтелә. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, 8 нче сыйныфлардан башлап әйдәп баручы рәсемнәр чын фотолар белән дә бирелә башлый.

Рәсем буенча фаразлагач, тыңланачак текстны кабул итү әллә ни авырлык тудырмый. Укытучы берәр сорау ярдәмендә кирәк фикерне табуга юнәлеш бирә, текст тыңлана, чөнки укучылар үз фикерләренең дөресме, юкмы икәнлеген ишетеп аерырга тиеш. (Бу мөһим эш төре өчен дисклар чыгарылды, мәктәпләр тәэмин ителде). Соңыннан дәреслектәге текст ачыла. Текстны сүзен-сүзгә тәрҗемә итеп утыруның кирәге калмый. Тексттан бик кирәкле 1-2 информация алу да җитә.

Дәреслектәге сораулар, биремнәр, төрле ситуацияләр чагыштыруны, анализлауны, логик фикерләүне таләп итүче күнегүләр системасын тәшкил итә. Бу күнегүләр гадидән катлаулыга таба бара. Бер үк лексик, грамматик материалның дәрестә 8-9 тапкыр кабатланып, аннан соң тема буенча 7-10 дәрес дәвамында кабатлана баруы сөйләм материалын истә калдырырга ярдәм итә. Материал дәреслектә уңышлы сайланган, актив лексикага корылган. Һәр тема элек үтелгән темалар белән бәйләнгән, шуңа күрә сүзләр, сөйләм үрнәкләре, грамматик структуралар гел кабатлана, активлаштырыла. Мәсәлән, инфинитив фигылнең ярый-ярамый, кирәк-кирәкми сүзләре белән сөйләмгә кертүне Шәвәли һәм Кирлемән үз кулларына ала. 6 нчы класста “Мәктәптә күңеллерәк!” темасы буенча инфинитив фигыль формасы активлаштырыла. Барлык, юклык формаларын таблица формасында кагыйдәләр дәфтәренә язабыз. Бу грамматик структура “Туган көнемә килегез”, “Әдәпле булу җиңелме?”, “Игелекле бул, балам!” темаларында да кызыл җеп булып сузылып бара: кунакка вакытында бару, ничек керү, исәнләшү, чишенү, өстәл артында үз-үзеңне тоту, транспортта бару да 2 герой киңәшләре аша бирелә.

Бу җөмлә калыпларыннан соң ситуатив күнегүләр тәкъдим ителә. Мәсәлән, представим, что кто-то бросил пальто на пол. Коммуникатив бурыч: как посоветуешь, что одежду надо

повесить на вешалку. Сөйләм үрнәге: Алеша, пальтоңны элгечкә эләргә кирәк. Барлык әдәплелек кагыйдәләре кабатланып чыккач, (бу, әлбәттә, 1 дәрестә генә түгел) сөйләмгә чыгабыз, үзебез турында сөйлибез: Син әдәпле кунакмы? Әйе, мин әдәпле кунак, чөнки мин киемне элгечкә эләм, ..., ..., ..., . Шушы ук үрнәк өстәл артында утыру, транспортта йөрү, авыру әбигә булышу, телефоннан сөйләшү дәресләре өчен кулланыла. Шулай итеп, төрле лексикадан төзелгән грамматик структуралар әледән-әле кабатланып килә, бер калыпка салына.

Иң әһәмиятле компетенция – социаль-мәдәни. Аны формалаштыру максатыннан УМКның роле зур. Татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен, этикет кагыйдәләрен кулланып аралашу белү сәләте ул – социаль-мәдәни компетенция. Халык авыз иҗаты әсәрләре, шушы халык өчен генә хас әйбер исемнәре, милли киемнәр, тарихи вакыйгалар, бәйрәмнәр, фразеологизмнар, гореф-гадәтләр – болар милли мәдәният үрнәкләре булса, сөйләм этикеты үрнәкләре: тәмле телле булу, кунак сыйлау, теләкләр теләү; риза булу-булмау, килешү-килешмәү, ышанмау, шаккату, кисәтүне белдерүче һәм башка үрнәкләрне төрле ситуацияләрдә куллануга, геройларга бәя биргәндә кулланырга тырышабыз. (Бу үрнәкләр копилкасы укучыларның кагыйдәләр дәфтәренең урта өлешендә туплана). Мин аларны тел чарлау этабында (блиц-сораудa: 22 нче мәктәптә укый, бүген 7 дәрес, син мороженое яратмыйсың, <u>математика</u> дәресендә кем дежур? фразалары аша), рольле күнегүләрдә: ты - мама, пожелай доброго пути перед школой; скажи, чтобы были умницами; как пригласишь к столу, пожелай приятного аппетита, поздравь с днем рождения, пожелай, чтобы родители были здоровы, пригласи друга на универсиаду в Казань, һ.б. Аннан шул ук теләкләрне миңа әйтергә кушам, чөнки 2 зат күплек санын да ныгытырга кирәк.

Дәреслектәге тагын бер мөһим моментка тукталасым килә. Һәр класс китабының форзацында кагыйдәләр таблицасы бар (без аларны аңлатучы текстлар категориясенә кертәбез). 5класста - исем, тартымлы исем, зат алмашлыклары төрләнеше; 6 нчы класста – 5 нче классныкына өстәп, сан төркемчәләре, билгеле, билгесез үткән заман хикәя фигыль, боерык, шарт фигыль төрләнеше, инфинитив ясалышы; 7нче класста – фигыль юнәлешләре, хәл фигыль төркемчәләре; 8 нче класста – Татарстан картасы, Казан шәһәре картасы. Бу тупланмалар очраклы түгел. Чөнки һәр класс китабына сюжет салынган. 5 нче класста исем, тартымлы исем, зат алмашлыкларын куллану бик актив, чөнки укучылар җәйге каникулдан килә, яңа укучы мәктәптәге балалар белән таныша; бала үзе, әти-әниләре, гаиләсе, холкы, гаиләдәге вазифалар белән таныштыра. 6 класста ел буе әдәплелек кагыйдәләре (кунакка бару, өйдәге тәртип, телефоннан сөйләшү әдәбе, буш вакытны файдалы үткәрү, һ.б.) буенча сөйләшү, киңәш бирү, бәя бирү формалары аша кулланыла, шуңа күрә боерык, шарт фигыль кулланышы бик кирәк; 7 нче класста – песи, этләр, кошлар тормышы, аларга ярдәм итү, бәйрәмнәр. Болар барысы да балаларга көндәлек тормышта якын темалар. 8нче класстагы сюжет: Булат авылга кайта, яңа дуслар таба, алар кайларда сәяхәт иткәннәр, нинди транспорт төрләрендә сәяхәт итү уңайлырак булу турында сөйләшәләр; Булатның әбисе Казанга килү турында хат яза ,(хат – эпистоляр жанр-БРТ кертелгән), әбине каршыларга бару өчен юл йөрү кагыйдәләрен белү кирәк; шәһәр белән таныштыра, бүләкләр, сувенирлар, киемнәр сайлый. 9 нчы класс материалы яхшы белем алуга юнәлеш бирә, шуңа “Сәләт”лагере, дуслар табу, үзара мөнәсәбәтләр һ.б. ассызыклана.

УМК-на “Без тарихта эзлебез” ярдәмлеге кулланыла. Бер үк темага материал 3 аспектта: дөньякүләм, Россия масштабында (рус әдәбияты, мәдәнияты) һәм Татарстан җирлеге материаллары аша чагыштырып бирелә. Мәсәлән, Кол Гали - Гомер; Клеопатра – Екатерина II - Сөембикә; археологлар тарафыннан торгызылган Помпеи (Римда) - Биләр - Болгар; изге чишмәләр: Израиль, Мисыр, Кызыл Чишмә.

Әйтелгәннәргә йомгак ясап, тагын өстәмә материаллар: күнегүләр җыентыгы (укытучыга), методик әсбап, диск, эш дәфтәре, электрон ресурс (презентацияләр) барлыгына искәртергә кирәк.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: УМК тулысынча түбәндәге таләпләргә туры килә: укучыларның яшь үзенчәлеге исәпкә алына; тышлыгы каты материалдан, төсле, матур

рәсемле, язулы, кызыктыргыч; әйдәп баручы төсле рәсемнәр, авыр булмаган канатлы сүзләр, балаларга мактау, яратып эндәшү сүзләре, бәйрәмнәр белән котлау үрнәкләре; кагыйдәләр дәреслектә кыскача, схема рәвешендә, бик катлаулы булмаган мисаллар белән бирелә; һәр тема башында бик матур сюжетлы рәсем, аның буенча мавыктыргыч эш төрләре, сүзлек, үрнәк диалог, монолог, уеннар, төрле кызыклы фактлар фәннең кызыклы, мавыктыргыч якларын күрергә, телебезнең төзеклеген, матурлыгын тоярга өйрәтүче күнегүләр; дәреслеккә өстәп укыту-методик комплект, мультимедия чаралары,эш дәфтәре, әзер тестлар; аерым-аерым, парлап, төркемләп эшләү өчен күнегүләр; төп, өстәмә (фәнни текстлар, документаль материаллар, фән һәм техника тарихыннан мәгълүмат, төрле казанышлар, белешмә материаллар), аңлатучы (сүзлек, кагыйдәләр җыелмасы, күрсәтмәләр, бирем тәрҗемәләре, тестлар) текстлар; сюжетлы, күләмле рәсемнәр, фотографияләр, төсләр палитрасы уңышлы сайланган. Балалар һәм әти-әниләр белән үткәрелгән анкеталардан күренгәнчә, Нигъмәтуллина Р.Р. авторлыгындагы “Татарча да яхшы бел” укыту-методик комплексы буенча дәресләргә әзерләнүдә бернинди авырлык кичермәүләрен белдерәләр. Гадәттә, укучылар өй эшләрен эшләгәндә чит кеше ярдәменә мохтаҗ була. Ә дәреслек материалы тулысынча өй эшендә чагылыш таба. Дәрестә телдән автоматлаштырылган лексик-грамматик материал эш дәфтәрләрендә язып ныгытыла.

2014-15 нче уку елында ук әлеге дәреслекләр китапханәләргә кайтты. Укытучылар өчен татар теленнән үрнәк программа Мәгариф һәм Фән министрлыгы сайтына урнаштырылды.

Файдаланылган әдәбият:

Нигъмәтуллина Р.Р. Татарча да яхшы бел.5,6,7 нче сыйныфлар – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015.

Рәхимов Ә.З. Психолого-педагогическая концепция школьного учебника.- Уфа: Творчество, 2000.- 36-42

Хәйдәрова Р.З. Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту. – Казан:Татарстан китап нәшрияты, 2015. – 3-4.

## ШАГЫЙРЬ КҮҢЕЛЕ – БАЛАДА

***Гәрәева Гөлчәчәк Шәрәфетдин кызы,***
*Кама Аланы 1 нче мәктәбенең директор урынбасары;*
***Гарипова Лилия Рәүф кызы.,***
*Каенлы мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*




“Милләт мәшһүр адәмнәр белән мәртәбәле”, - дигән мәгърифәтче, галим Ризаэтдин Фәхреддин. Аның бу гыйбарәсе якташыбыз, язучы, депутат, абруй һәм лаеклы хөрмәт яулаган, зыялы шәхес, милләтебезнең йөзек кашы Разил Исмәгыйль улы Вәлиев турында әйтелгән кебек.

Разил Исмәгыйль улы Түбән Кама районы һәм шәһәрендә, милләтебезнең язмышы өчен кайгыртып, мәдәният йортлары төзү, китапханәләр ачу, мәктәпләр төзекләндерүһәм киләчәк буынны тәрбияләүгә зур ярдәм күрсәтә. Төбәгебездә һәр елны Разил Исмәгыйль улы Вәлиев

исемендәге яшь иҗатчылар бәйгесе оештырыла. Разил Вәлиев, шәһәр һәм район күләмендә мәктәп яшендәге балалар арасында иҗади бәйге үткәреп, тантаналы төстә үз премиясен тапшыра. Аның бу гамәле, беренчедән, язучының яхшы кеше булуын искәртсә, икенчедән, премиягә ия булган укучыларның милләтебезнең зыялы улы кулыннан диплом, истәлекле бүләк, я булмаса акчалата премия алулары күңелләрен киләчәктә иҗатка рухландыру, җаннарын җылыту булып тора. Бәйгегә укучылар тарафыннан шигырьләр, әкият, хикәя, парча һәм башка жанрда язылган әсәрләр тәкъдим ителә. Аларның иҗатында туган якка мәхәббәт, балачакның сихри мизгелләре, яшьлектәге самими йөрәк хисләре чагылыш таба.

Иҗатта югары нәтиҗәләргә ирешкән балалар өчен оештырылган бу бәйге инде 19 нчы тапкыр үткәрелде. Шушы дәвердә бәйгедә 2000 гә якын бала үзенең каләмен сынаган.

Бәйгенең “Шагыйрь күңеле – балада” дип исемләнгән быелгы йомгаклау тантанасы 24 нче мартта И. Садыйков исемендәге балалар һәм яшьләр иҗат сараенда уздырылды. Әлеге шигъри бәйрәмдә бәйгегә катнашкан укучылар, иҗади җимешләрне бәяләгән мөхтәрәм жюри, шәһәр җитәкчеләре, милләтебезнең хөрмәтле шәхесләре, мөгаллимнәр катнашты. Бу матур чара җыр-бию, күңелләрне рухи баета торган шигырьләр белән үрелеп барды. Кичәнең иң матур мизгелләре булып, әлбәттә, бәйгедә катнашкан 59 баланың хезмәтләрен бәяләү булды. Иҗатта үзләренең каләмнәрен сынаган, аны бәйгегә тәкъдим иткән бер генә бала да читтә калмаган, һәркемгә яраткан шагыйрьләре истәлекле бүләкләр бирде. 19 укучы махсус номинацияләрдә җиңүчеләр дип табылды.

Иң сәләтле, әдәбият дөньясы капкаларын ачарга әзер торучы җиңүчеләр 33 нче гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы Усманова Лилия,11 нче мәктәпең 6 нчы сыйныф укучысы Дәүләтшина Венера булса, 13 нче мәктәпнең 11 нче сыйныф укучысы Сабитова Таңсылу абсолют җиңүче дип билгеләнде. Бу укучыларның иҗат җимешләре мәртәбәле жюри һәм, иң мөһиме, Разил Исмәгыйлевич тарафыннан югары бәяләнде. Укучылар истәлекле бүләкләргә, җиңүче дипломнарына ия булды.

Разил Исмәгыйлевич - безнең горурлыгыбыз, өметебез дә, милли байлыгыбыз да. Аңа иң олы рәхмәтебезне җиткерәбез һәм һәр елны шушы бәйгенең дәвам ителүен көтеп калабыз.

## КӨЙЛЕ, МОҢЛЫ ТАТАР ҖЫРЫ” –КОНКУРЕНТЛЫККА СӘЛӘТЛЕ БӘЙГЕ

***Садыйкова Лидия Хәмдегали кызы,***
*31 нче мәктәпнеңмилли мәгариф өчен җаваплы директор урынбасары,*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*




Түбән Кама муниципаль район мәктәпләре арасында уза торган “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесе быел 9нчы мәртәбә үткәрелде. Аның чишмә башы 2008 нче елга барып тоташа. Татар халык, классик, заман җырларын популярлаштыру, сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру, халкыбызның милли үзенчәлекләре, күркәм сыйфатлары үрнәгендә яшь буынны тәрбияләү, буыннар бәйләнешен тәэмин итү, сәхнә сәнгатен, башкару осталыгын үстерү, туган телгә, татар халкының композиторларына, шагыйрьләренә һәм аларның әсәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләү максаты белән үткәрелүче бу бәйгенең дәрәҗәсе елдан ел үсә генә бара.

Аның хуҗасы һәм иганәчесе - Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама муниципаль районы бүлеге рәисе, шәһәр советы депутаты, “Шинник” спорт комплексы директоры - Ганиев Рөстәм Мәҗит улы. Татар җыры аша укучылар күңеленә сеңгән сүзләр беркайчан да онытылмый, ди ул. Чыннан да, 2016-2017нче уку елы дәвамында барган “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесендә генә дә Түбән Кама муниципаль районы шәһәр һәм авылларыннан 1049 укучы бала..., ягъни 37 җыр коллективы, 21 ансамбль үзара милли җырларыбызны башкару осталыгында көч сынашты.Димәк, әнә шуның кадәр укучы баланың күңеленә милли мәрҗәннәр тезелде дигән сүз. Алай гына да түгел, бүгенге көндә мәктәпләр үзләре генә башкарып чыга алмаслык зур эшләр дә башкарыла бит әле, 9 ел дәвамында Рөстәм Мәҗит улы ярдәме белән шәһәребез мәктәпләре 182 милли кием тектергәнен уйлап карасак, әлеге бәйгегә тиңнәр юклыгына инанырбыз! Ә кайбер мәктәпләрнең ел саен диярлек җиңү яулауларын исәпкә алсак, бу бит милли мәгарифне үстерү юнәлешендә чын табыш дигән сүз.

Һәр уку елындагы кебек, быел да жюри тарафыннан урыннар билгеләү җиңел генә булмагандыр, бу эштә иң мөһиме – гаделлек дип әйтер идем мин. 2016-2017 нче уку елында алар тарафыннан җиңүче итеп билгеләнгән мәктәп коллективларына сокланмый мөмкин түгел.

III урында: 1-4 нче сыйныф укучылары арасында - 32 нче гимназия һәм 6 нчы мәктәп укучылары; 5-6 нчы сыйныф укучылары арасында – 8 нче мәктәп укучылары; 7-8 нче сыйныф укучылары арасында – 3 нче мәктәп укучылары; ансамбльләр арасында Зур Афанас мәктәбе укучылары.

II урында:

1-4 нче сыйныф укучылары арасында – 14 нче лицей укучылары; 5-6 нчы сыйныф укучылары арасында – Муса Җәлил исемендәге 1 нче гимназия укучылары; ансамбльләр арасында - 10 нчы мәктәп һәм 13 нче гимназия-интернат укучылары.

I урынга лаек коллективлар: 1-4 нче сыйныф укучылары арасында - 10 нчы мәктәп укучылары; 5-6 нчы сыйныф укучылары арасында - 33 нче мәктәп укучылары;7-8 нче сыйныф укучылары арасында - 35 нче лицей коллективы; ансамбльләр арасында абсолют җиңүче - 33нче мәктәп укучылары. Аларга Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге һәм Түбән Кама муниципаль районы мәгариф идарәсе исеменнән “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесенең I дәрәҗә лауреат дипломы, махсус әзерләнгән статуэтка һәм Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге исеменнән акчалата премияләр тапшырылды.

Алдагы – 2017-2018 нче уку елында – әлеге бәйгенең юбилее булачак. Бу - ун еллык эш нәтиҗәләренә йомгак ясалачак дигән сүз генә түгел, ә бәлки, бәйгедә катнашу тагын да кызыграк булачак дигән сүз дә.

# ОБРАЗОВАНИЕ
## НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**УЧРЕДИТЕЛЬ**
Управление образования Исполнительного комитета
Нижнекамского муниципального района РТ

**ПРЕДСЕДАТЕЛЬ РЕДАКЦИОННОГО СОВЕТА**
Матюшин В.Н. **-** начальник управления образования Исполкома НМР РТ

**ГЛАВНЫЙ РЕДАКТОР**
Офицерова А.М. **-** заместитель начальника управления образования НМР РТ

**РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ**
Рамазанова А.Р. - заместитель начальника управления образования НМР РТ
Сабирова Г.М. – методист управления образования НМР РТ
Исмагилова Р.Р. - методист методист управления образования НМР РТ
Кирпичонок М.А. **-** директор МАУ ДО «Межшкольный учебный комбинат» НМР РТ
Санникова З.А. **-** директор МБУ ДО «Центр внешкольной работы» для одаренных детей» НМР РТ
Гимашева А.Х. – методист МАУ ДО «Межшкольный учебный комбинат» НМР РТ

**МАКЕТ, ДИЗАЙН И ВЁРСТКА**
Бормотов Д.Н. **-** дизайнер МАУ ДО «Межшкольный учебный комбинат» НМР РТ
Телефон: 30-85-66
E-mail: muk-nk@yandex.ru.

**КОРРЕКТОРЫ**
Кирпичонок М.А. **-** директор МАУ ДО «Межшкольный учебный комбинат» НМР РТ
Санникова З.А. **-** методист управления образования НМР РТ
Сабирова Г.М. - методист управления образования НМР РТ
Гараева Г.Ш. – заместитель директора по национальному образованию МБОУ «Камскополянская СОШ №1» НМР РТ
Масаллимова М.М. - учитель татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ
Фаттахова И.И. - учитель татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия-интернат №13» НМР РТ
Габдуллина К.Т. - учитель татарского языка и литературы МБОУ «СОШ №27» НМР РТ

**АДРЕС РЕДАКЦИИ**
423570, Республика Татарстан,
Нижнекамск, ул. Мурадьяна 18а
Телефон: 30-85-66
Электронная почта: muk.nk@tatar.ru; muk-nk@yandex.ru